Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы
Башкарма комитетының мәгариф идарәсе
Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының
Зеленодол муниципаль районы җирле оешмасы
«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының
5 нче номерлы гимназия»
муниципаль бюджет гомуми белем
бирү учреждениесе

# «А.Шамов укулары»



## V төбәкара укулар материаллары

**Яшел Үзән, 2019**



**Яшел Үзән сандугачы – Динә Гарипова**

«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 11нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» БМББУ,5нче сыйныф

Кереш

*Бер генә булса да җыр белмәгән һәм бер тапкыр да җырлап карамаган кеше бар микән бу дөньяда? Мөгаен, юктыр. Чөнки җыр – сәнгатьнең киң таралган һәм яратып башкарыла торган төре. Ул кешене гомере буена озата бара: кайгы-хәсрәттә дә, шатлык-куанычта да.*

*Җыр – ике сәнгать чишмәсе: шигърият һәм музыка кушылудан туа. Элегрәк "җыр" атамасын "җыру" формасында да кулланганнар. Атаманың бу формасын җыр текстларында, мәкаль-әйтемнәрдә, өлкән буын кешеләре сөйләмендә әле бүген дә очратырга була.*



*Җырларның туу тарихы ерак үткәнгә барып тоташа. Күп гасырлар элек, әле дөньяда беренче китаплар гына түгел, ә беренче язу ысуллары барлыкка килгәнче үк, кешеләр җырны да, шул җыр ритмына башкарыла торган биюләрне дә белгәннәр.*

Динә Гарипова 1991 елның 25 мартында Яшел Үзән шәһәрендә медиклар гаиләсендә туа. Әтисе, Фәһим Мөхәммәт улы, әнисе, Әлфия Газизҗан кызы- медицина фәннәре кандидатлары.Динәнең әтисе яшь вакытта музыкага сәләтле булган. Ул лирик романслар башкарган. Динә дә музыкаль сәләтне әтисеннән алган. Динәнең абыйсы Булат Гарипов, музыканы да бик яраткан. Динә Гарипова музыка белән бик иртә шөгыльләнә. 6 яшендә Динә "Алтын микрофон" җыр театры укучысы була. Яшел Узән шәһәренең 1 нче номерлы мәктәбендә белем ала. Көчле тавышы белән ул укытучыларын һәм остазларын таң калдыра. Конкурсларда һәм фестивальләрдә катнаша. Аның музыка өлкәсендә беренче җитди казанышы 1999 елга туры килә. Динә бу конкурста «Жар-птица» Бөтенроссия яшь башкаручылар конкурсы лауреаты була. Төрле республика, бөтенроссия һәм хәтта халыкара конкурсларда катнашып,призлы урыннар яулый.2001 нче елда "Йолдызлык" республика

фестивалендә 1 дәрәҗәле лауреат исеменэ була. 2008 нче елда Динә Гарипова “Алтын микрофон” театры артистлары белән Франциядә катнаша.

Казан федераль университетында "Алтын микрофон» жыр театрын тәмамлый. Шуннан соң Динә Татарстанның халык артисты Габделфәт Сафин белән гастрольләргә китә. 18 яшь тулгач, ул Роман Оболенскийның продюсерлык студиясе белән контракт төзи, аның белән берничә ел хезмәттәшлек итә. 2010 елда ул туган Яшел Үзәндә беренче сольный концерт бирә. Динә Гарипова «Кышкы эстрада» исемле шәһәр конкурсында катнаша һәм Гран- при яулый. Динә Гарипованың репертуарында татар, рус . итальян һәм француз телләрендә җырлар була..

Динә Гарипова "Голос" проектында»




2012 ел җырчы Динә Гарипова өчен борылыш елы була. Ул Беренче канал«Голос " популяр вокаль конкурсында катнаша.Шул ук елда Татарстан Республикасының Президенты Рөстәм Миңнеханов указы буенча Динә Гариповага “”Татарстан Республикасының атказанган артисты” дигән мактаулы исем бирелә.

Динә Гарипова «Евровидение»дә

Динә Гарипова Мальмада узган «Евровидение» Халыкара вокаль конкурсында катнашырга чакыралар . Бу аның өчен бик шатлыклы хәбәр була. Конкурс өчен җырны озак сайлый.Җырны бик сәнгатьле һәм ышанычлы башкарып , 156 балл җыеп, финалга утә. Шул ук елны “Евровидение-13” финал конкурсында катнаша. Динә 174 балл җыеп , 5 нче урынга лаек була.

Динә Гарипова карьерасы чәчәк ата. Дебют альбомы

2013 елда Динә «Риф»мультфильмын куюда катнаша. 2014 елда Динә Гарипованың дебют альбомы чыга.

Динә Гарипова Александр Стефановичның «Кураж " фильмында катнаша. Бу 12 серияле фильм Алла Пугачеваның  тормышына һәм иҗатына багышлана. Динэ фильмда яңгыраган барлык җырларны да башкара..

2016 елда Динә «Күңел» дип аталган яңа җыр тәкъдим итә. Бу композициягә музыканы ул  үзе яза.

Йомгаклау

Җыр туа, җыр яши, җырлаучысы булганда – җыр мәңге яши. Җыр ул – яшәү чарасы. Җыр – ул халыкның җаны. Үзенең теле булмаган халык булмаган кебек, үзенең җыры, музыкасы һәм музыка уен-кораллары булмаган халык та дөньяда юк.
Кешенең туганнан алып бөтен гомере җыр һәм музыка белән тыгыз бәйләнештә уза. Ул иң элек бишек җыры тыңлап үсә. Соңрак кеше тормышында уен, хезмәт һәм көнкүреш җырлары киңрәк урын алып бара.

Җыр – ул рухлану, җыр – ул матурлыкка соклану. Җыр кешенең юлдашы. “Җырсыз кеше – канатсыз кош” – ди халык.

Җыр – кешенең балачагыннан алып соңгы гомеренә кадәр аерылмас юлдашы. Җыр яраткан кеше матурлыкны ярата. «Халык иҗатын белми торып, хезмәт халкының чын тарихын белеп булмый», - дигән бөек рус язучысы М.Горький.

Үз халкыңның улы яки кызы булу өчен аның гореф-гадәтләрен, җыр-моңнарын, әкият-дастаннарын, күп гасырлы тарихын, әхлак, тәрбия тәртипләрен ана сөте белән сендереп үсү кирәк.     Музыка – хисләр теле ул.

**Җанга якын туган җирем**

Сабирова Илүзә,
Әйшә урта мәктәбенең
VII сыйныф укучысы

Туган җир! Туган авыл! Йөрәккә нинди якын һәм кадерле сүзләр! Безнең һәрберебезнең дә газиз туган йорты, туган авылы бар. Һәр авылның үзенә генә хас кабатланмас, истә кала торган урыннары күп. Сокланып туймаслык тугайлары, челтерәп ага торган йөгерек чишмә буйлары, балыклы күлләре, куе камышлар белән уратылган елга-үзәннәре, туган ягыбызның кырлары, басулары, шаулап торган урманнары күңелләргә рәхәтлек биреп, туган туфракка мәхәббәт тәрбияли. Шушы матурлыкка сокланып, челтерәп аккан чишмәләрнең җырына кушылып кемнәр генә җырламаган да, кайсы гына шагыйрь бу турыда шигырь язмаган, кайсы гына композитор көй чыгармаган, батыр ир-егетләрнең, сылу кызларның даны кайларга гына таралмаган икән! Шуңа күрә аның һәр сукмагы, һәр агачы, елга-күле күңелгә якын, шунлыктан туган авылыбыз, туган җиребез күз карасыдай кадерле һәм газиз безгә.

Кая гына барсак та, нинди генә матур урыннарны күреп соклансак та, туган төбәгебезнең гүзәллеген берни дә алыштыра алмый. Тәпиләп киткән, беренче тапкыр "әттә-әннә" дип әйтергә өйрәнгән вакытта ук күңел түренә туган телебез аша кереп утырган ул кадерле урыннар…

Туган авыл гомер-гомергә кешеләр өчен илһам чыганагы, яшәргә көч һәм дәрт бирүче күңел маягы булып торган.

Авылым, гүзәл табигатькә, киң күңелле кешеләргә бай булган туган авылым! Синдә тудым, синдә үсеп, синдә канат чыгарып киләм. Бу авылда тууым, синдәге кешеләрнең бер-берләренә булган яхшы мөнәсәбәтләрен күреп, шулар арасында тәрбияләнүем белән чиксез бәхетле мин.

Нинди генә кеше булмасын һәм кайда гына тумасын, һәркемгә дә үзенең туган ягы кадерле дип уйлыйм. Чөнки мин үзем дә башка җиргә чыгып китсәм, үзебезнең Яшел Үзәнебезне, Әйшәбезне сагынып кайтам. Анда кайчандыр бик искә алмаган гади генә нәрсәләр дә кадерле була башлый. Авылыбызның куе урманнарына чыгып җиләк, гөмбә җыю үзе бер рәхәт! Мондагы табигатьнең матурлыгын сүз белән генә аңлатырлык түгел. Ә инде җәелеп киткән ямь-яшел тугайлары авылдашларым өчен илһам чишмәсе булып тора.

Эчкерсез, гади, гадел, мәрхәмәтле, ачык йөзле, югын табыштыручы, барын уртаклашучы кешеләре белән дә чиксез горурланам мин.

Туган як, туган туфрак, туган җир, туган ил, туган тел! Безнең өчен гадәти төшенчәгә әйләнгән бу сузләр читтә яшәүче милләттәшләребез өчен тагын да тирәнрәк мәгънәдә яңгырый икән. Бигрәк тә ерак чит илләрдә гомер итүче татарларның туган ягын бер күрергә тилмереп, бөтен күңеле белән туган илгә омтылып яшәүләре турында ишеткәч, йөрәк сыкрап куя. Ә менә

безгә үз туган җиребездә яшәвебезгә шатланып, шуның кадерен белеп, ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен өйрәнеп, аларны яңартып яшәү мөмкинлеге күбрәк бирелгән. Бу мөмкинлекне файдалану туган ягыбызның чәчәк атуына китерер, тормышыбызны тагын да ямьлерәк итәр дип ышанасым, сезгә изге теләкләремне җиткерәсем килә. Туган ягыгызны яратыгыз, үткәне һәм киләчәге белән кызыксынып яшәгез, туган телегезне, туган җирегезне хөрмәт итегез, аны онытмагыз!

**Рөстәм Галиуллин – балалар язучысы.**

Татарстан Республикасы Арча муниципальрайоны
муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе
“Иске Чүриле урта гомуми белем мәктәбе”нең 4 нче сыйныф

**Кереш**

Укытучым белән А.Шамов укуларына күзәтү ясаганнан соң, без “Замана язучысы” дигән темага тукталдык. Сәбәбе ни дә соң дип уйларсыз? Үзебезнең җирлектә иҗат итүче, күрше авыл егете Рөстәм Галиуллин иҗатын тирәнрәк өйрәнәсем килде.

Без бу иҗади хезмәткә тулысынча алынганчы, аның балалар өчен язылган хикәяләрен барладык. Рөстәм Галиуллин иҗатын яктырткан мәкаләләр белән таныштык.

Кулымда – Рөстәм Галиуллин хикәяләре. Яшь булса да, Рөстәм Галиуллин балалар әдәбияты өлкәсендә аеруча зур уңышлар казанган. Ул нәниләр дөньясы белән яши, үсеп килүче буынның таләпләрен аңлый, үзенең киңәшләрен бирә, каләм белән безне тәрбияли, балаларның матур хатирәләрен үреп бирә.

Темабыз“Рөстәм Галиуллин – балалар язучысы”.

Үз алдыма Рөстәм Галиуллинның балалар өчен язылган хикәяләрен барлауны максат итеп куйдым. Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар билгеләнде:

- Рөстәм Галиуллинның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү;
- Балалар өчен язган хикәяләрендә тәрбия мәсьәләләрен табу;
- Өйрәнелгән материаллар беләняшьтәшләремне таныштыру;
- Балалар язучыларының иҗатын тирәнтен өйрәнү;

Максатка ирешү өчен без түбәндәгеләрне башкардык:

- Рөстәм Галиуллинның китапханәдә булган китапларын барлап чыктык.
    - Балалар өчен язган хикәяләрен укыдык.
    - Гәҗит, журнал,өстәмә әдәбият һәм интернет чыганаклар аша табылган материалны тикшердек.

Тикшерү объекты - Рөстәм Галиуллин иҗаты.

Тикшерү предметы – Рөстәм Галиуллин - балалар язучысы.

Хезмәтем керештән, төп өлештән, йомгаклау һәм әдәбият исемлегеннән тора.

**Төп өлеш**

**Рөстәм Галиуллинның тормыш һәм иҗат юлы**

Рөстәм – укытучылар гаиләсеннән. Әнисе Нурсөя апа – татар теле һәм әдәбияты, әтисе Госман абый математика укытучысы. Егеткә бу да йогынты ясамый калмагандыр, мөгаен. Ул әнисеннән әдәбияткә, телгә булган яратуны алса, әтисеннән математикларча төгәл фикер йөртүне кабул иткән. Өстәвенә ул ике апа белән үскән төпчек малай. Ул – күзәтүчән, вакыйгаларга мыек астыннан гына елмаеп, жор теле белән бәя бирүчән. Бер карасаң, аның төп геройлары хикәянең үзәгендә дә түгел. Алар күбрәк читтәнрәк, урабрак йөриләр, ләкин барыбер үз дигәннәренә ирешәләр.

Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетын кызыл дипломга тәмамлый һәм, шунда ук аспирантура узып, кандидатлык диссертациясен яклый.

Казан дәүләт университетына укырга кергәч, “Әллүки” әдәби – иҗат берләшмәсе утырышларына йөри башлый. Менә шунда инде ул иҗат эшенә чума.

Студент елларыннан аның юморескалары, повестьлары, хикәяләре, балалар өчен шаян хикәяләреТатарстан, Россия һәм чит ил матбугатында дөнья күрәбашлый.Әсәрләре рус, төрек, кыргыз, казакъ, якут һ.б. телләргә тәрҗемә ителә.

2005 елдан юморескалары, хикәяләре «Сабантуй» газетасында, «Чаян» журналында, соңрак «Казан утлары», «Идел», «Мәйдан» журналларында, «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга», «Татар дөньясы» (Мәскәү) газеталарында басыла. 2008 елда беренчекитабы —

«Гипнозчымалай» дөньякүрә.Хикәяләре урыстелендә «Литературная газета», «Татарский мир», «Наш современник» басмаларында урын ала.Тәрҗемәбеләндәшөгыльләнә. А. Сәхибзадинның («Апологет»), Р. Мирхәйдәровның («Мартук», «Җәяүлесәйран», «Җәяүле татар») һ.б. әсәрләрентәрҗемәитә.2009 елда ТРязучыларберлегенә алына.(Р. Зәйдулла, Г. Садә, Л. Лерон тәкъдимебелән). 2016 елда «Атаһәмул» әсәре «Русияхалыкларыныңбүгенгепрозасы» антологиясенәтәкъдимителде.

Укыганвакыттаук «Чаян» журналында, «Шәһри Казан» газетасындаэшли.2009 елдан Шәһри Казан газетасындабүлекмөхәррире.

2010 елның 1 ноябреннән Казан утлары журналыныңбүлекмөхәррире.

2011 елның 16 декабреннән 2014 елның ноябренә кадәр «Идел» журналы мөхәррире.

Татарстан Фәннәракадемиясенең Тел, әдәбиятһәмсәнгатьинститутында гыйльмисәркатипвазыйфасынбашкара.

2018 елның гыйнварыннан «Казан утлары» журналының баш мөхәррире.

Рөстәм Галиуллин яулаган үрләр:

- 2006 «Иделемакчарлагы» бәйгесендә I урын.
- 2007 «Иделемакчарлагы» бәйгесендә Гран-при.
- 2007 Арча районы якташлыгыҗәмгыятепремиясе.
- 2009 «Бәллүркаләм» бәйгесеҗиңүчесе («Дебют» номинациясендә).
- 2009 ГарифАхуновпремиясе (Арча районы).
- 2009 ТРхөкүмәте гранты.
- 2011 ТРяшьләр, спорт һәм туризм министрлыгыһәм ТР татар-башкорткөрәшефедерациясеуздырганәдәбиконкурста III урын («Чәчмәәсәр» номинациясендә).
- 2015 Муса Җәлилпремиясе — «Юллардаҗилакиде» китабыһәм татар әдәбиятынүстерүгәкерткәнхезмәтеөчен».

## Мавыктыргыч мажаралар...

Әйдәгез мавыктыргыч мажаралар дөньясына – “Мин...үзем йөздем”, “Вәгъдә батырлары”, “Биш икеле”, “Яраткан почмак”, ”Мин беренче”,“Җиңүче каз”лар яшәгән илгә аяк басыйк, анда барган кызыклы вакыйгаларның тере шаһитлары булыйк, үзебезгә яңа дуслар- танышлар табыйк.

“Вәгъдә батыры ” хикәясендә Марат сыйныфташларын алдамакчы була. Хәйлә “ятьмәсен” бик оста үрә ул: ”... Компьютердан дискка уеннар яздырып бирәм, тегене алып киләм, моны эшлим.... Бик күп алар!.. Илдар үзе дә шакката дустының шундый ялганчы булуына.

- Болай кеше алдалап йөрмә, барыбер бер килеп кабарсың, - дип һәрчак кисәтә ул аларны”. Ләкин аның бу астыртын эшен сыйныфташы Илдар бик тиз сизеп ала. Ялган вәгъдәләр таратырга ирек куймый. Хикәя соңында Вәгъдә батыры- Марат иптәшләренең кармагына эләгүен сизми дә кала :

“- Менә шулай, “ вәгъдә батыры”, йөри торгач тәки килеп каптың бит, - диде бит, - диде...” Ярый әле безнең сыйныфта Марат кебек “Вәгъдә батыр”лары юк.

“Биш икеле” хикәясе бигрәк тә кызык. Бу хикәя юморга корылган дип әйтсәк тә була. Көлмичә генә укып булмый. Дәресне тыңлап утырмау,өй эшен эшләмәү аркасында Азат сыйныфташлары алдында көлкегә кала. Бу көн аңа бигрәк тә уңышсыз була. Биш фәннән биш “икеле” ала ул. География дәресендә :

“ ... - Иң җинел сораудан башлыйм, - диде укытучы. – Россияне тап! Җиңел, имеш! Иң авыр сорау бу! Кая посты икэн инде ул Россиясе?

Раниянең кулын уңга таба селкүен күреп, таягыншунда төртте. Тик юкка! Башта Көньяк Америка материгында “йөргән” Азат бу юлы Африкада иде.

- Син нәрсә, энем, негр мәллә? – дип пыр тузды укытучы. – Картаның зур өлешен алып торган Россиягә ялгыш кына булса да таяк очы эләгер иде берәүнең...”

Геометрия дәресендә Хәлим абый йоклап утыручылардан сорады. Алар арасында Азат та бар иде. “Ялганчы” кушаматлы Марат аркасында

“Гипотенуза галимгә әйләнде”. Геометрия  дәресеннән өзек китерәм: “Шулай да  урта рәтләрнең берсендә утыручы “Ялганчы” кушаматлы Маратның, пышылдап: “Гипотенуза – галим ул!” дигәнен ишетте. Әлеге бик тансык сүзләр аңа көч бирде. Үз – үзенә ышанып сөйләргә тотынды:

- Гипотенуза ул – бөек галим. Аның хезмәтләре - .... – Классның егыла – егыла көлүеннән туктап калып, Азат Хәлим абыйсына карады. Укытучы, “икеле” дигәнне аңлатып, ике бармагын күрсәтеп тора иде.” Бу юлларны укыганда, ничек инде көлмисең?!

Татар телендәге килешләр дә бик борчыды аны : “ Килешнең нәрсә икәнен исенә төшерә алмады Азат, өмет тулы күзләрен Раниягә төбәде. Кыз башына төртеп күрсәткәч:

- Баш э...э.. килеш ...э...э... – дип мыгырданды.
- Әйе, әйе, дәвам ит.

Икенчесендә Рания ияген тотты.

- Э...э... Ияк килеш, - дип әйткәнен сизми дә калды Азат.
- Нәрсә?! Муен килеше түгелме тагын? Син, җиденче класска җитеп, икенче класстан бирле һәр ел кабатланган алты килешне әйтә алмый торасың! Китер көндәлегеңне! – диде укытучы, пыр тузып”.

.... Ә бичара көндәлек барысын да кичерә, түзә.

“- Мә, тот , энем, көндәлегеңне! Буш калган соңгы графасын да тутырдым, - дигәч, үзен кызганудан күзенә яшьләр килде малайның ”

Бу хикәяне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: бирелгән эшкә җавапсыз карау, дәресне күңел биреп тыңламау сыйныфташларың алдында уңайсыз хәлдә калдыра. Һәр эшне вакытында эшләп барырга кирәк.

Ә “Яраткан почмак” хикәясен укыганда, балалар бакчасы искә төште.Хикәя ике шук малайның хыяллары турында бара. Минемчә, балалык  шуклыклары һәр укучының күңелендә саклана торгандыр. Һәркемнең тизрәк үсәсе килә бит. Рөстәм абый гына гади генә хәл – вакыйгадан көтелмәгән кызык таба белә : “... Ике дус планнарын тормышка ашырырга да керештеләр. Иң уңайлы вакытны көтеп, тавышсыз – нисез генә мәктәпкә шылдылар. Икенче катта

шау-шу ишетеп, шунда менделәр. Анда линейка бара икән. Берсен – берсе бүлеп кычкырган тавышлар ишетеп, алар якынрак елыштылар.

Директор, завуч һәм укытучылар – барысы да бишенче сыйныфта укучы Фаязның абыйсы – Саматны, Илнурның абыйсы - Ильярны дәрескә йөрмәгәннәре, “ике”ле алганнары һәмтәртипсез булганнары өчен пыр туздырып сүгәләр иде. Абыйларының башлары түбән иелгән, йөзләре кып – кызыл, күзләре өметсез. Моны күреп Фаяз белән Илнурның котлары очты:

- Монда тагын да начаррак икән! – диде Фаяз.
- Ычкыныйк яхшы чакта, - дип өстәде Илнур.

Алар тиз генә бакчаларына элдерттеләр һәм мыштым гына инде төшләренә керә башлаган, керфекләрен йому белән күз алдына килеп баскан газиз, якын почмакларына барып бастылар...”

“Җиңүче каз” хикәясе бигрәк тә үзенчәлекле. Маҗаралар яратучы Рифат, Фәрит, Айрат ата казлары арасында ярыш оештыралар. Шунысы кызык: һәр казның кушаматы бар. Акмуен, Каратәпи, Пәһлеван. Иң башта җирәбә салалар. Җирәбә буенча Рифатларның казы белән Фәритләрнеке көч сынашырга булдылар. Малайлар ут йотып тордылар: бөтенесе һич көтмәгәнчә тәмамланды. Ярыш башлануын көтеп торганда, Пәһлеван, кинәт борылып, артында басып торган Айратка килеп ябышты! Канатлары белән, ярсып – ярсып суккан килеш, малайның бот тирәсеннән умырып алды. Тешләве шулкадәр кинәт булды ки, каушавыннан катып калган малай, аңышып, кушаяклап авылга таба элдертте. Аның артыннан бу мәгънәсез уеннан тәмам туйган һәм нык ярсыган Пәһлеван да калмады. Өйләренә кайтып җиткәнче куды ул аны. Айрат аңардан капкаларын ябып кына котылды. Пәһлеван күзләрен ялтыратып койма ярыгыннан карап торган малайга мыскыллы карашын ташлады да башын югары чөеп, су буена – гаиләсе янына ашыкты....

“Мин ....үзем йөздем!” хикәясендәге герой йөзәргә өйрәнә. Маратның иптәшләре кебек рәхәтләнеп күлдә коенасы,йөзәсе килә, тик батырмын дип курка. Ләкин абыйларының ярдәме белән ул йөзәргә өйрәнә. “Марат

бертуктаусыз кычкырды, ярдәм сорады, чәбәләнде. Бераздан, үзенең батмаслыгына инангач, ярга карады. Үз күзләренә үзе ышанмады ул: нибары биш-алты адым калган! Ике ягыннан бераз ара калдырып йөзеп барган абыйлары үзара көлешеп куйдылар. Марат аларның сүзләрен юньләп ишетмәде дә. Яр буена килеп җитеп, аяклары җиргә тиюгә, дулкынланудан һәм хәле бетүдән телен көчкә әйләндереп:

- Күрдегезме.... күрдегезме... мин .....мин үзем йөздем! – дип пышылдады!

“Мин беренче” хикәясе тулысынча юморга корылган. “Беренче булу”, “Менә күрәсезме”, - дигән мактану сүзләре һәрбер үсмердә була: “Бирелеп тыңлап утырган Зөлфия апага күршесе:

- Карале, кем баласы соң анда бар көченә акыра? Үзе башкалардан берничә сүзгә алда да бара! – дип әйткәч, аның Рөстәм икәнен таныды ул.

Чыннан да, аның тавышы аермачык булып ишетелеп тора, һәм калганнар белән тигез җырламый да иде. Ул арада җыр тамамланды Дулкынланган, күзләреннән очкын чәчелгән Рөстәм әнисе янына йөгереп килде дә, барысына да ишетерлек итеп:

- Әни, ишеттеңме, мин беренче җырлап бетердем! – диде.

Зөлфия апа ни көләргә, ни мактарга белми аптырап калды...”

Рөстәм абый үз хикәяләрендәге геройлар – Илдар кебек акыллы,Фаяз белән Илнур шикелле хыялый, Рөстәм төсле тырыш, Рифат, Фәрит, Айрат кебек шаян,Марат сыман кыю булырга чакыра. Ул гади вакыйгаларның үзенчәлекле мизгелен тотып ала һәм сәнгатьчә матур итеп сурәтләп бирә. Аның хикәяләре йөгерек, җитез укыла.

## Йомгаклау

### Балачак мизгелләре гомер буе озатып барачак...

Минемчә, Рөстәм Галиуллин хикәяләре башка авторлар иҗатыннан аерылып тора. Ул баланы кызыксындыру максатыннан төрле формаларга мөрәҗәгать итә, мавыктыргыч ачышлар ясый һәм, гади генә хәл-вакыйгада да балаларча көтелмәгән кызык таба белә. Әйтерсең, автор әле һаман балачакта яши. Рөстәм Галиуллин балалар дөньясын якыннан белә, аны шул ук нәниләргә җиткерү өчен төрле ысул һәм әдәби алымнардан уңышлы файдалана.

Эш барышында мин үз максатыма ирештем дип уйлыйм. Икенче бүлектә Р.Галиуллин иҗатына күзәтү ясалды, аның әсәрләрендәге тәрбияви эчтәлек ачылды.Эшнең барышында бу теманың шактый мавыктыргыч булуына инана төштем. Яшь булса да, Р.Галиуллин иҗаты шулкадәр бай, матур, кызык икән! Әсәрләре белән танышуы гына да ни тора. Һәрбер әсәре аның үзенчәлекле, күңелгә ятышлы. Ләкин Рөстәм Галиуллин иҗаты тәнкыйть күзлегеннән, язучылар, галимнәр тарафыннан өйрәнелә башламаган. Минемчә, ул бөтен җаны белән – балалар язучысы.

**Якташыбыз Фәрит Валиуллин -күренекле рәссам-монументалист**

А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицейның

5 нче сыйныф укучысы

Миннулина Чулпан Гомәр кызы

**Кереш**

Йолдызлар никадәр күбрәк булса, күк йөзе шулкадәр серлерәк һәм матуррак. Берсеннән- берсе балкыбрак янган бихисап йолдызлы Яшел Үзән күгендә рәссам-монументалист Фәрит Рәшит улы Вәлиуллин да бар. Яшел Үзәнне йолдызлы күк белән чагыштыруыбыз очраклы түгел.Чыннан да, Яшел Үзән районы- иҗатлы сәнгатьләргә бай төбәк. Аның гүзәл табигате, шифа һавасы 1998 нче елда рәссам Фәрит Рәшит улын тартып китергән. Менә инде 21 ел инде ул гаиләсе белән безнең шәһәрдә яши, шәһәребезне бизи, матурлыкны безгә өләшә. Бүгенге көндә якташыбыз Вәлиуллин Фәрит Рәшит улы -күренекле рәссам-монументалист, Татарстан, РФ рәссамнар берлеге, ЮНЕСКО сынлы сәнгать халыкара берлеге әгъзалалары, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты.

Шуңа күрә фәнни эшемнең **максаты** итеп, **якташым Фәрит Вәлиуллинның тормыш юлын өйрәнү, аның иҗатын пропагандалау. итеп куйдык.** Максаттан чыгып без үз алдыбызга түбәндәге **бурычлар**ны куйдык:

- якташыбызның иҗатын ачу;
-төрле темаларга багышланган рәсемнәрен барлау;
- алардагы төп темаларны ачыклау

**Темамның актуальлеге**: Яшел Үзән районында иҗат итүче якташыбызны пропагандалау, аны яшьтәшләремә җиткерү.

**Тикшерү объекты** итеп, Фәрит Вәлиуллин турында язылган вакытлы матбугат (“Яшел Үзән”, “Зеленодольская правда”, “Мәдәни җомга” гәҗит материаллары, “Идел”, “Идель”(рус телендә) журнал, интернет материаллары файдаланылды.

**Фәнни эшнең практик әһәмияте:** рәсем дәресләрендә, рәсем сәнгать мәктәбендә өстәмә чыганак итеп кулланырга мөмкин.

Әлеге эшне башкарганда түбәндәге **метод-алымнар** кулланылды: күзәтү, гомумиләштерү, тикшеренү, **рәссам белән әңгәмә**, эзләнү, анализлау, нәтиҗә ясау.

**Фәнни эшнең структурасы**. Фәнни эш керештән, төп өлешнең дүрт бүлегеннән, йомгаклау, кулланган әдәбият исемлегеннән, кушымтадан тора.

**1 нче бүлек. Фәрит Вәлиуллинның тормыш юлы**

Фәрит Вәлиуллин 1959 нчы елның 24 нче февралендә Казанның Иске Татар бистәсендә дөньяга килә. Балачагы башкалабызның гүзәл Әҗем мәчете тирәсендә уза. Бирегә һәр җәйне кулларына мольберт тоткан рәссамнар җыела, ә нәни Фәрит абый сәгатьләр буена дөньясын онытып, аларның әлеге гүзәллекне киндергә күчерүләрен күзәтә. Шушы рәвешле ул сәнгать дигән тылсымлы дөнья белән очраша.Үз куллары белән матурлыкны чагылдыру теләге Фәрит абыйны сәнгать мәктәбенә алып килә. Казан сәнгать мәктәбен "бик яхшы" билгеләргә генә тәмамлый. Бу мәктәптә Фәрит абыйны талантлы педагоглар, мәсәлән, Майоров Борис Иванович укыта.Ә ул Казан нәкыш мәктәбе буенча күп эшләүче педагог була.

Училищены бетереп, 1980 нче елда Фәрит Вәлиуллин 3 нче һәм 5нче номерлы сәнгать мәктәбендә укыта. Ә 1980 нче елда В.И.Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать инситутына укырга керә. Һәм аны 1886 нчы елда тәмамлый. Мәскәүдән аны Түбән Камага эшкә җибәрәләр, рәссамнар иҗади төркем җитәкчесе булып эшли.

**1998** нче елда Яшел Үзәнгә кайта. Ике кызы да безнең лицеебызны тәмамлый. 2001 нче елдан рәссам сәнгать әгъзасы итеп сайлана.

2006 нчы елдан бүгенге көндә кадәр Фәрит Рәшит улы Вәлиуллин Татар дәүләт гуманитар-педагогика университының (хәзер КФУ) дизайн һәм сынлы сәнгать факультытында рәсем укытучысы, доцент, Россия рәссамнар берлеге, ЮНЕСКО сынлы сәнгать халыкара берлеге әгъзасы.

## 2 нче бүлек . Якташыбыз - күпкырлы талант иясе

Фәрит Вәлиуллин портрет, пейзаж натюрморт, монументаль сәнгать жанрларында эшли. Түбән Камада Әфганстанда һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл, Түбән Кама үзәк хастаханәсе каршында Габдулла Тукай комплексы стелласын ясый.

Казан шәһәрендә Кол Шәриф мәчете гөмбәзенең эчке бизәлешен башкара. Бизәлештә кояштан эре тюльпан чәчәкләренә әверелүче зур-зур нурлар бар. Чәчәкнең эчендә Аллахы исемен белдерүче өч билге: Кояш, балкыш нурлар.Үзәктәге "Бисмилла" сүзе мозаика төзеп ясалган. 2016 нчы елда Фәрит абыйга шушы эше өчен (башка рәссамнар белән берлектә) Габдулла Тукай премиясе лауреаты исеме бирелә.

Рәссам Казан тимер юл вокзалы фасадын яңадан төзәтеп кору иҗади төркемнәр җитәкчесе дә булып эшли. Ул -"Татар кызы" орнаменты авторы.

Яшел Үзәнебезнең Җәмигъ мәчете фасады, “Тынычлык” мәчетенең фасадын да ясаучы  - барысы да якташыбыз Фәрит Вәлиуллин эше.

Фәрит абый әле портретлар остасы да. Ул җырчылар  Лидия Әхмәтова, Гөлзада Сафиуллина портретларын ясаган, бүгенге көндә Сара Садыйкова портретын тәмамлый.

Фәрит абыебыз әле нәкышче дә, монументчы да.

Рәссам шәһәребезнең Фаил Шәфигуллин китапханәсенә  Бакый Урманче портретын  бүләк итә.Ул китапханәнең диварында урын алган.

**3 нче  бүлек. Рәссам - монументалист иҗатында төп темалар**

Фәрит Вәлиуллин  иҗатында  күбесенчә тарих  темасы  ала.

Шундый кызыклы мәгълүматка тап булдык. Өч рәссам  -Фәрит Вәлиуллин, Рифкать Вахитов һәм Равил Зәһидуллин Алтын Урданың объектив яктыртмавына, фильмнарда кимсетелеп күрсәтелүенә, халыкның тарихи белемсезлегенә борчыла. Бергә җыелып, фикер алышканнан соң, рәссамнар Алтын Урда чорына багышлап күргәзмә оештыралар.

Рәссам “Болгар” тыюлыгындагы Ак мәчет бинасында  “Болгарның исламны кабул итүе”мозаика панносын ясау  иҗат төркеме җитәкчесе дә икән. Аның буе 2 м, киңлеге 6 м.

Фәрит абый- тарихны белүче яхшы белгеч. Без моны  аның тарихка кагылган картиналарында күрдек: “Сөембикә һәм Үтәмешгәрәй” “Яугир шатлыгы”, “Ибн- Фадланнның килүе”, ”Иске шәһәр”. Аның картиналары туган якка мәхәббәт белән сугарылган. Рәссамның күңеленә табигатьнең һәр фасылы якын. Бу күренешләр аның “Кич”, “Яз”, “Печән өсте” һ.б  картиналарында чагылыш тапкан. Картиналарында милли рух беркелә . Бу бигрәк тә “Сабантуй” картинасында ачык.

Фәрит абый әле портретлар остасы да. Ул җырчылар  Лидия Әхмәтова, Гөлзада Сафиуллина портретларын ясаган, бүгенге көндә Сара Садыйкова портретын тәмамлый.

**4 нче бүлек. Фәрит Валиуллинның эшләре( хезмәте) күргәзмәләрдә**

Якташыбызның күп картиналары илебезнең зур шәһәрләрендә -Мәскәү, Санк-Петербург, Түбән Новгород, Чувашия, Башкорстан һ.б., чит илләрдә- Франция, Төркиядә , ә Яшел Үзәнебездә шәхси күргәзмәләре 1999 нчы елда ике тапкыр,  “Курай тавышы ишетелә” ( 2006), “Моңлы курай- ( 2014, 2016)

елларда үткәрелә.Шулай итеп, яшел үзәнлеләргә якташыбыз **биш тапкыр** күргәзмә оештыра, ә бу исә халкыбызга матурлык өсти.

## Нәтиҗәләр.

Без бу (беренче тапкыр) фәнни- тикшеренү эшемне эшләгәндә үз алдымыбызга куелган максатыма ирештек дип уйлыйм. Киләчәктә үзебезнең тикшеренү эшебезнең өстендә киңрәк эшләргә җирлек бар.Чөнки якташыбыз һаман нәрсәдер эзләнә, яңа картиналар өстендә эшли. Ә без аның иҗатын белән кызыксынуыбызны дәвам итәрбез.

## Йомгаклау.

Парижда “Татарстан күге астында” дип исемләнгән күргәзмәдә катнашучы якташыбыз белән ничек горурланмыйсың инде?! Әйе, якташыбызның иҗатын **пропагандалау** кирәк дип саныйбыз, чөнки:

1. Фәрит Вәлиуллин- күпкырлы шәхес.Ул портрет, пейзаж, натюрморт, монументаль сәнгать жанрында эшләүче рәссам, нәкышче
2. Фәрит абый- тумыштан рәссам, иҗат белән укытучылык эшен дә үреп алып баручы, эзләнүчән иҗатчы, тарихчыларның кинәшчесе.
3. Якташым Фәрит Вәлиуллин иҗатында күбесенчә тарих, пейзаж темасы урын алган.

Фәрит Рәшит улы Вәлиуллинның Яшел Үзәндә күргәзмәсен көтеп калабыз.

**“Ленар Шәех иҗатында милләт язмышы”**

Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль

районы А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицей”

муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

Башкарды: Галәвиева Камилә

4 нче сыйныф

**Кереш**

Мин татар! Һәм мин бу сүзне башымны күтәреп, горурланып әйтәм. Горурланырлык та шул. Тукае, Җәлиле, Сәйдәше, Туфаны... булган горур милләт баласы мин.

Мин үземнең җырлы-моңлы туган телемә, горур милләтемә чын күңелдән бирелгән. Чиста, саф татар телендә сөйләшәм, Татарстан җирендә яшим.

Минем фикерем буенча, милләтне ярату, аның белән горурлану туган телне белүдән башлана. Чөнки баланың теле ана теле белән ачыла. Эзләнү эшенең темасы итеп, Ленар Шәехне сайлап алуым да юкка гына түгел. Аның күп кенә шигырьләрендә милләт язмышы яктыртыла. Ул чын күңеленнән үзенең халкы, милләте өчен борчыла. Эзләнү эшемнең төп максаты итеп, Ленар Шәехнең иҗатына күзәтү ясауны алдым. Шуннан чыгып, мин берничә бурычны билгеләдем:

1) Шагыйрьнең язган шигырьләрен , китапларын барлау, аларны укып өйрәнү, аларга үз мөнәсәбәтемне белдерү;
2) Ленар Шәехнең милләт турында язган шигырьләренә анализ ясау;

Минем эзләнү эшем хәзерге көндә дә актуаль дип уйлыйм, чөнки хәзерге вакытта безнең туган телебездә сөйләшүче яшьләр дә бик сирәк. Практик әһәмиятенә килсәк, бу эзләнү эше белән төрле чараларда чыгыш ясарга мөмкин. Мәсәлән, туган тел көненә багышланган чараларда, Ленар

Шәехнең милләт язмышы турында язылган шигырьләрен укып, татар халкын “уятырга” мөмкин дип уйлыйм. Мин әле “Гыйлем фест” дип аталган проектлар бәйгесендә дә катнаштым. Анда проектны яклап, үз телемнең әһәмияте турында чыгыш ясадым.

## Төп өлеш.

### 1. Ленар Шәехнең иҗатына күзәтү.

Ленар Шәех балалар өчен иҗат итүче шагыйрь. Аның шигырьләре һәркем өчен аңлаешлы, җиңел укыла. Ул – балалар өчен “Авылдан килгән мендәр”, “Керпе ничек энәле булган?”, “Безнең ишегалдында” , “Безнең урманда” (2017) исемле китаплар авторы.

Ленар Шәех 2013 елда Татарстан Республикасының Муса Җәлил исемендәге Республика премиясенә, 2017 елда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге әдәби премиясенә лаек була. 2015 елда «NEWBOOK.Волга – 2015» Идел буе әдәби премиясе лауреаты була. 2017 елда Швециянең Стокгольм шәһәрендә узган VI Халыкара "Open Eurasian Literature Festival & Book Forum" әдәби фестивалендә "Әдәби әсәр" категориясендә "Кече проза" номинациясендә икенче урынны ала. 2018 елда Халыкара Евразия премиясенең алтын лауреаты дигән исем бирелә. Ленар Шәех – 2007 елдан Татарстан Язучылар берлеге, 2012 елдан Татарстан Язучылар берлеге идарәсе, 2016 елдан «Евразия иҗат гильдиясе» (Лондон) әгъзасы.

### 2. Ленар Шәех шигырьләрендә милләт язмышы.

Татарлыгым – горурлыгым,

Йолдызның иң ачыгы,

Көннең иң нурлы кояшы,

Иртәнең иң саф чыгы...

Татарлыгыңнан кимсенмә,

Бүтәннәрне кимсетмә!

Татар булып калсаң гына

Газиз милләтең бетмәс!

Аның әлеге шигыренә зур мәгънә салынган. Туган телебез – безнең горурлыгыбыз, ди. Аны иң чиста чык тамчысы, иң якты йолдыз белән чагыштыра. Автор халыкны үз телеңнән кимсенмәскә, аны яратырга кирәк, ди. Шул очракта гына, безнең телебез озак яшәячәк, дип әйтә. Чөнки туган телебезнең киләчәге безнең үзебездән тора. Ленар Шәехнең“ Уян татар” шигырендә ул татарларга киңәш бирә, үз телеңә битараф булмаска чакыра. Безнең телебез гаҗәеп матур. Аның күп гасырлык тарихы бар. Борынгы заманнарда безнең бабаларыбыз үз телләре, үз милләтләре өчен көрәшкәннәр. Автор, әлеге шигырендә туган телеңне онытсаң, ата-бабаларың хурланыр, дип яза.

Уян, татар!..

Уян халкым!..

Күтәрел!..

Бу хәлеңдә бабаң күрсә,

үртәлер.

Алда безне бик күп эшләр

көтәдер,

Татар булсаң, татарлыгың

күтәр бер!..

Ленар абый, татар халкын “уянырга” өнди. Әгәр дә без бирешеп торсак, безнең телебез бетәчәк, безгә баш бирмәскә, күтәрелергә кирәк, ди.

Автор берничә шигырендә “татарлык” сүзен куллана. Татарлыгыңны үзеңнең исемең белән генә түгел, ә гамәлләрең белән күрсәт, диясе килә.

...«Әннә», – диеп ачылмаса

Сабый теле,

Киләчәктә кем аңлар соң,

Телем, сине?..

Сабый беренче сүзләрне әнисеннән ишетә. Баланың беренче сүзе дә "әннә". Һәр халык үз телен яратып "Ана теле" дип атый. Автор, әгәр дә сабыйның беле "әннә" дип ачылмаса, ул туган телен белмәячәк , ди.

Авыл саклый синең тирән

Тамырыңны.

Ә шәһәрдә «Явыз Иван»

Ябырылды.

Аның "Сала теле" дип аталган әлеге бүгенге көндә бик актуаль дип уйлыйм. Чөнки мин үзем дә урамда, кибетләрдә, транспортта татар сөйләмен бик сирәк ишетәм. Ә Ленар абый әйтүенчә, ана теле беренче урында булырга тиеш..Шуңа күрә үз телебездә иркен, курыкмыйча сөйләшергә тиешбез.

Йомгаклау.

Ленар Шәехнең иҗатында милләт язмышы дигән теманы алуым очраклы түгел. Мин үз милләтемне яратам һәм хөрмәт итәм. Үз телемдә иркен аралашам, үз телем белән горурланам. Әти- әнием миңа үз телемне өйрәтеп үстерделәр.

Әлеге эзләнү эшемдә без Ленар Шәехнең шигырьләрен анализладык. Нәтиҗәгә килеп, Ленар Шәех милләт язмышы, туган телебезнең киләчәге, гореф-гадәтләребезне, динебезне саклау өчен язылган шигырьләре милли үзаңны уята. Үз милләтебезгә мәхәббәт тәрбияли.

**Ленар Шәех иҗатының тәрбияви роле**

Гомумбелем
муниципаль бюджет учреждениесе

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль

районы 1 нче Лицей

Хабибуллина Арина Артур кызы, 4сыйныф

1. Кереш

Яраткан шөгылем – китап уку. Мәктәп һәм китапхәнәдән алып төрле китаплар укыйм, аларны әти-әниемә , сеңелемә сөйлим. Уку дәресләрендә без бик күп шагыйрьләр, язучылар , аларның әсәрләре белән танышабыз. Мин үзем бигрәк тә шигырьләр укырга яратам. Үземә ошаганннарын ятлыйм да. Ленар абый Шәех шигырен бик ошаттым:

Яхшы, уңай сыйфатлар
Сездә, зыялы затлар!
Һәммәгез тыйнак, матур,
Әхлаклы,гадел,батыр,
Тәрбияле, тәртипле,
Тәүфыйклы, юмарт, ипле;
Акыллы, тырыш, башлы,
Намуслы, кыйгач кашлы,
Тәвәккәл, кыю җанлы,
Бәхетле, шат һәм аңлы;
Ачык, юньле, гөнаһсыз,
Инсафлы, кара яксыз,
Ихтирамлы, абруйлы,
Ягымлы, чиста уйлы;
Нәзакәтле, вөҗданлы,

Эшчән, җитез һәм данлы,
Олы җанлы, йөрәкле –
Җәмгыятькә кирәкле...

Торам башымны иеп,
Шундый булсаңчы диеп.

Ни өчен аның шигырьләрен сайлап алдым? Чөнки аның иҗатында төрле темаларга кагылышлы кызыклы шигырьләре ошады, күптән борчыган сорауларыма җаваплар таптым.Һәм аның әсәрләрендә матур, ягымлы сүзләр күп куллануына игътибар иттем. Бу миндә зур кызыксыну уятты. Кем ул Ленар Шәех? Аның геройлары кемнәр? Бу ягымлы сүзләр нинди мәгънәләргә ия? Укытучы апам белән эзләнү эше башланып китте.

Минем эзләнү эшемнең исеме “Ленар Шәех иҗатының тәрбияви роле”

Эшнең максаты: Ленар Шәех иҗаты аша шигырьләрен өйрәнү, тәрбияви ролен ачыклау.Максатка ирешү өчен иҗаты белән таныштым; шигырләрен, әкиятләрен укыдым, өйрәндем.

Тикшерү объекты булып Ленар Шәехның шигъри иҗаты, китаплары алынды.

Тикшерү методлары – күзәтү, анализ, нәтиҗә ясау.

Эшнең төзелеше – кереш, төп өлеш, төп өлеше ике бүлектән, йомгаклау һәм әдәбият исемлегеннән тора.

## 2. Төп өлеш

### 2.1Ленар Шәехның тормыш юлы, иҗаты

Шагыйрь Ленар абый 1982 нче елның 4 октябрендә Актаныш районы Такталачык авылында дөньяга килә. 1998 нче елда Такталачык урта мәктәбен, 2002 нче елда Минзәлә педагогия көллиятен , 2007 нче елда Казан дәүләт университетын тәмамлый. Студент булган вакытларда ук төрле газета-журналларда журналист булып эшли. Иң беренче булып студентлар арасында “Тәрәзә” дип аталучы газетаны оештыра. Ленар абый балалар өчен

“Авылдан килгән мендәр”(2005), “Керпе ничек энәле булган?”(2007), “Безнең ишегалдында”(2012), “Алдамыйм!” (2014),”Безнең урманда”(2017) һәм башка китаплар авторы.

2017нче елда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге әдәби премиясе лауреаты.

## 2.2Ленар Шәех шигырьләрендә тәрбияви үзенчәлекләр

Ленар Шәехның иң беренче хайваннар турындагы шигырьләренә игътибар иттем. Аны сеңелемә дә укыдым. Хайваннар дөньясы “Безнең ишегалдында” китабында күрсәтелгән. Әлеге китапта шагыйрь нәниләрне авыл ишегалдында яшәүче кош – кортлар, хайваннар белән таныштыра. Анда комда коенучы күркә дә, күлгә таба йөгерүче үрдәк тә, ара-тирә бакчага кергәләп чыгучы кәҗә дә, ишегалдын саклаучы эт тә һәм башка күп кенә йорт хайваннары һәм кошлары бар. Бу китап бик мавыктыргыч, чөнки анда шигырьләр иллюстрацияләр белән баетылган. Аларны укырга рәхәт тә, кызык та.

Шулай ук “Ни өчен куянның колагы озын?” әкиятендә шагыйрь табигатькә соклана, ике зур җәнлекне чагыштыра, куянның куркаклыгын күрсәтеп бирә.

Шагыйрьнең автор – төзүче буларак башкарган “Җил каян килә?” китабы аеруча игътибарга лаек. Ул балалар һәм яшүсмерләр өчен кызыклы фәнни-популяр басма булып тора. Бу җыентыкта табигать күренешләренә аңлатма бирелә. Мәсәлән, челлә, буран, яңгыр кебек табигать күренешләрен ничек килеп чыкканлыгы турында кызыклы фактлар, иң кызыклы сорауларга җаваплар бар. Әлеге җыентыкта башка авторларның да шигырьләре урын алган.

Ленар Шәех үзенең иҗатында балаларның өлкәннәргә карата ихтирамлы, инсафлы булып үсүләренә басым ясый. Мәсәлән, “Әнинең киңәше” шигырендә, әни кызын тегергә, чигергә өйрәтә. “Сәет бабай” шигырендә

шагыйрь “хәрәкәттә-бәрәкәт” дип, хемәтне мактый. Бабай сиксән яшьтә булуына карамастан ул шук, шаян, тырыш, тапкыр итеп сүрәтләнгән. Эшләгән эшләренә сокланып, егетләргә сөенеп яшәгән Сәет бабай образы күрсәтелгән.

Балалар шигъриятендәге эзләнүләре дә кызыклы гына. Мәсәлән, “Авылдан килгән мендәр” китабындагы шигырьләре төрле яшьтәге балаларга адресланган. Ел фасылларына кагылышлы шигырьләр, бишек җырлары, мәктәп тормышындагы кызыклы вакыйгалар да, гаиләдәге мөнәсәбәтләр дә, дуслык, дөреслек турында уйланулар да чагылыш тапкан.

Шагыйрь балаларның акыллы, зирәк, эшчән булып үсүләрен тели, уңай сыйфатлар тәрбияли. Мәсәлән “Уңай сыйфатлар” шигыре бик кызык, мавыктыргыч итеп язылган, шигырь тулаем итагатьле сүзләрдән тора. Бу шигырьдә “яхшы” сүзен 40 төрле синоним сүз белән алыштырган. Минем дә шундый акыллы, ягымлы, чын мәгнәсендә тыйнак татар кызы буласым килә.

Шулай ук балалар өчен язган шигырьләре табигать күренешләрен, ел фасылларын, ай, йолдызларны сурәтли. Ул ел фасылларының килүен аеруча матур итеп, серле итеп яза: Кояш нурлары Елмая, көлә

Битне сыпыра Чибәр Язбикә

Кыш үпкәләгән - Шатлык, сөенеч,

Елапутыра. Килә бит җиргә.

Тәрбияви үзенчәлекләрне Ленар Шәех иҗатында күп күрергә мөмкин. Мәсәлән, ялкаулардан көлү, батырлыкны күрсәтү, тапкыр, җитез булырга өндәгән шигырьләре күп. Бу шигырьләр балаларны дуслыкка, мәрхәмәткә өйрәтүче, тугры юл күрсәтүче булып торалар. Миңа аның шигырләре бик ошый. Алга таба да аның иҗатын өйрәнүне дәвам итәрбез.

## 3. Йомгаклау

Ленар Шәехның шигырьләре безне – балаларны гаиләңне яратырга,тапкыр, җитез,мәрхәмәтле кеше булырга өнди.Ул балаларны тәрбиягә, эш эшләп үсәргә өйрәтә. Ул аларны шаян шигырьләре аша күрсәтә. Һәр бала әдәбият дөньясына әкиятләр, шигырьләр аша килә. Үзенең шигырьләре аша шагыйрь

тәрбияләп кенә калмый, белемнәрен арттыра һәм сөйләм телен камилләштерергә алына. Ленар Шәехнең шигырьләре балаларга аңлаешлы, мавыктыргыч, яттан өйрәнү өчен җиңел.

**Хыялын тормышка ашыручы кыю кыз.**

Яшел Үзән муниципаль

районы 1нче номерлы Лицей

6а сыйныф

укучысы Дәүләтшина Сәмирә Раил кызы

Кереш

Яшел Үзән районы – татар халкына бик күп шөһрәтле ул һәм кызлар бүләк иткән төбәк. Бу яктан атаклы язучылар да, шагыйрьләр дә, төрле фән өлкәләрендә эшләгән абруйлы галимнәр дә аз чыкмаган. Каюм Насыйри, Афзал Шамов, Идрис Туктар, Азат Вергазов, Шәриф Сайкин, Гомәр Саттаров, Резидә Төхвәтуллина, Рәшид Кәлимуллин, Лариса Дяткова кебек атаклы кешеләр исемнәре генә дә ни тора!

“Хыялын тормышка ашыручы кыю кыз ” дип исемләнгән фәнни-тикшеренү эшемә түбәндәге максатларны куям:

1. Районыбыз белән бәйле күренекле шәхесләрне эзлекле өйрәнү.

2.Туган җиргә мәхәббәт, туган төбәккә бәйле күренекле кешеләргә хөрмәт һәм горурлану хисләре тәрбияләү.

Эшемнең төп бурычлары:

- якташ җырчыбызның җырларын, эшчәнлеген һәр укучы күңеленә сеңдерү;
- шул шәхесләр үрнәгендә һөнәр сайлауда ярдәм итү;
- мәктәптәге укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү.

Яшел Үзән җиреннән мондый олуг шәхесләрнең чыгуы юкка гына түгелдер. Моңа, миңа калса, төбәкнең искиткеч гүзәл табигате, суларының шифалылыгы, һавасының сафлыгы белән аңлатырга кирәктер. Мондый урында яшәгән кешеләрнең дә күңелләре саф, киң һәм иркен була. Бары шундый кешеләр генә илгә үз халкы өчен җан атучы, талантлы шәхесләр бүләк итә ала.

Лəкин монда тагын бер хикмəт бар. Безнең Яшел Үзəн кешелəре, беренче карашка ук, гадилеге, кунакчыллыгы, һəм иң мөһиме, зыялылыгы, затлылыгы белəн аерылып тора. Чөнки алар – татар халкына Сөембикəне биргəн данлыклы Йосыф мирза ыруының дəвамчылары. Ханбикəлəре белəн шушы төбəккə күчеп, җирле татарларның да иң асыллары белəн генə кушылганнан соң ничек бу җир, бу халык мəшһүр шəхеслəр тудырмасын?

Көчле рухлы кыз-Динə Гарипова.

Яңа гына калыккан сəхнə йолдызы - япь-яшь Динə Гарипова 1991нче елның 25мартында Яшел Үзəн шəһəрендə табиблар гаилəсендə дөньяга килə. Əтисе Фəрит Мөһəммəт улы Гарипов, əнисе Əлфия Газизҗан кызы Гарипова. Икесе дə санэпидемстанция табиблары, медицина фəннəре кандидатлары. Абыйсы Булат Гарипов кечкенəдəн хорда җырлый, мəктəпне тəмамлагач юрист һөнəрен үзлəштерə, полициядə хезмəт итə. Кечкенəдəн матур тавышы һəм музыкага сəлəте була. “Җыр сəнгате белəн кайчан таныштың?”- дигəн сорауга Динə болай дип җавап бирə: “ Мин 6 яшьтəн музыка түгəрəгенə йөрдем. Шулай кечкенəдəн җырларга яратам. Үсə төшкəч шəһəребездəге «Алтын микрофон» иҗат төркемендə шөгыльлəндем. Иптəшлəрем белəн күп кенə сəхнəлəрдə чыгыш ясадым. Хəтта, чит иллəргə дə барып чыктык без. Билгеле, бəйгелəрдə дə катнаштым. Республикада «Йолдызлык-Созвездие» бəйгесендə олы Гран-при белəн бүлəклəндем.” Вокал буенча укыткан мөгаллимəсе дə Динəне яратып искə ала: “Бездə беренчелəрдəн булып Динəнең абыйсы укыды. Абыйсын мактап əтисенə сөйлəгəч, əтисе əле аларның кызлары булуын һəм аның тагын да сəлəтлерəк булуы турында елмаеп əйтте”-ди. Динə Гарипова минем кебек үк Яшел Үзəн шəһəренең иң əйбəт 1нче номерлы лицеенда белем ала. Аның беренче укытучысы Любовь Денискина да тыйнаклыгы, тыныч булуы һəм аеруча гуманитар фəннəрне: рус теле, рус əдəбияты, инглиз теллəрен яратып өйрəнүен искə ала. “Татарча җырлыйсыңмы соң?”-дигəн сорауга исə Динə болай дип җавап бирə: “Əйе, Казандагы бəйгедə Гран-при яулагач татар җырларын башкаручы Габделфəт Сафин ансамблендə эшлəдем. Иң яраткан җырларым «Гөлҗамал»,

«Кыр казлары», «Пар алка», «Былбылым» дигән җырлар”-дип санап китә ул. Идел буе федераль университетының массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институтын читтән торып тәмамлый. 1999нчы елда Иваново шәһәрендә “Жар птица” исемле Бөтен Россия күләмендәге конкурста беренче дәрәҗәдәге лауреат исемен ала. 2001нче елда Республикада «Йолдызлык-Созвездие» бәйгесендә олы Гран-при белән бүләкләнә. Шушы җиңүләрдән соң Динәне күп кенә конкурсларга чакыра башлыйлар. 2005нче елда Эстониянең Тарту шәһәрендә узган халыкара конкурста лауреат исеменә лаек була. 2008нче елда “Алтын микрофон” иҗат төркеме белән Франциядә узган халыкара конкурста гран-при иясе булалар. 2009нчы елдан Роман Оболенский продюссерлык студиясе белән берлектә Яшел Үзәндә Динә Гарипованың 2010-2012нче елларда сольный концерты була. Аның репертуарында русча, инглизчә, татарча, итальянча, французча җырлар бар. Төп иҗат юнәлеше эстрада җырлары. Шулай ук ул рок стилендә дә үзен сынап карый дисәк тә була.

2012нче елның 29 декабрендә Динә Гарипова үзенең искиткеч матур тавышы белән Россия телевидениесе тамашачыларының мәхәббәтен яулады . Россиянең үзәк телевидениесендә өч ай буе дәвам иткән «Голос» дип аталган җырчылар җыенында финалга җитеп җиңүгә иреште якташыбыз. Яшел Үзән халкының шулай бердәм сөенешүен күптән күргән юк иде. Яшел үзәнлеләр үзара очрашып сөйләшкәндә якташларының уңышына соклану һәм гаҗәпләнү, горурлану һәм ярату кебек хисләрен белдерергә ашыкты. «Кызыбызның җырлавын мөкиббән китеп тыңлаган телевизор караучылар аны башкалардан өстен чыгарды »-дип искә ала әнисе кызы турында.

Бер әңгәмәдә шушы җиңүе турында Динә болай дип искә ала: “ Мин ул гаҗәеп олы тамашада үземне беренче сыйныф шәкерте кебек хис иттем. Бик дулкынлана идем, билгеле. Ничек тынычлана алдым дисәгез - мөгаллимем Александр Градский киңәшләре бик ярдәм итте миңа. Ул бит: “Сәхнәгә чык та, бернигә карамыйча, үзең белгәнчә җырыңны башкар!” - дип өйрәтте. Һәм мин тәҗрибәле җырчының киңәшен тотарга тырыштым инде.

Әле хәзер дә мин җиңүемә ышанып җитмим кебек. Чөнки башкалар да данга лаек дип исәплим. Бары тик алар бүтән төр җырлар башкардылар.” “Юниверсал” җырлар яздыручы чит ил компаниясе белән эшләү мөмкинлеге бүләк итеп бирелә аңа. Динәнең әнисе Әлфия ханым гаиләсе турында болай сөйли. “Динәнең җырлау сәләте әтисеннән дип уйлыйм, Фәһим яшьрәк чагында гармунда уйнап үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә җырлап йөри иде. Ирем белән икебез дә медицина белгечләре без. Мин мондагы медицина көллиятендә укытам, ирем исә Казанда укытты... Улыбыз Булат та музыканы ярата, фортепьянада уйнарга өйрәнде. Өйләнеп Казанда яши. Килен белән бергә менә сеңлесенә бик нык ярдәм итәләр алар. Динәнең дусларына да рәхмәтле без: шул ук Мәскәүдә, бәйге вакытында, фатир мәсәләсендә кыенлык килеп чыкмады - аны дус кызы үзе янына сыендырды. Балаларыбыз өчен куанып яшибез инде. Динә безне бик яшьли сөендерә башлады үзе: Иваново шәһәрендәге бәйгедә катнашып зур приз алып кайтуын әле дә хәтерлибез. Аңа сигез яшь кенә иде әле ул чагында...”

2012нче елның 30декабрендә Татарстан Республикасы президенты Рөстәм Миңнеханов указы нигезендә Динәгә Татарстан Республикасының атказанган артисты исеме бирелә. 2013нче елның 19февралендә Россиядән “Евровидение-2013” конкурсында катнашачагы билгеле була. 2013нче елның 14маенда финалга чыга. 18майда исә конкурсның финал концертында бишенче урынны алу бәхетенә ирешә. 2013-2014нче елларда Россиянең зур шәһәрләрендә Динә Гарипованың гастрольләре гөрләп уза. 2014нче елның 30октябрендә Мәскәүнең “Крокус Сити Холл” сәхнәсендә үзенең “Мәхәббәткә ике адым” дип исемләнгән дебют альбомын тәкъдим итә. Шул ук елны Динәгә Александр Стефановичның “Кураж” исемле сериалында уйнау бәхете елмая. 2015нче елның февраленнән Александр Градцкий җитәкчелегендәге музыкаль театрның актрисасы булып эшли башлый. Соңыннан “Күңел”, “Бишенче элемент”, “Син минем өчен” дигән синглларын тәкъдим итә.

Динәнең шәхси тормышына килгәндә, 2015нче елның августында тормышка чыга. Тормыш иптәше якташы Равил Бикмөхәммәтов.

## Йомгак.

Әйе, иҗатчы җырчымы ул, композитормы – иң беренче нәүбәттә кешеләр йөрәгенә иман, игелеклелек орлыклары салырга тиеш. Сәнгатьнең теләсә кайсы төренең иң югары күрсәткече – халык күңеленә юл таба алу. Мондый сәләткә ия кешеләр сирәк очраса да, нәкъ менә алар мәдәниятебезнең, җәмгыятебезнең яшәешен һәм үсешен билгели, халыкның рухи хәзинәсен баета. Тормышның һәр мизгелен, табигатьнең серле яшәешен, кешеләр күңелен нечкә йөрәгең аша үткәреп музыка телендә әйтә алу - ул зур бәхеттер. Җырчының кайсы гына җырын алма, алар табигыйлеге, аһәңле һәм моңлы булуы белән аерылып тора. Үзенә карата артык таләпчән, максатына ирешү өчен өзлексез иҗат утында янып, үзе сайлаган сәнгать юлында баручы тынгысыз кыз ул Динә Гарипова.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: һәркем үз язмышын үзе яза. Тәкъдирдә язылганны көтеп ятсаң, ихтимал, бәхет үзе сине эзләп килеп җитә алмас. Динә өчен бәхет – җыр-музыка, газиз халкыңа хезмәт итү. Якташыбыз Динә Гарипова – чын мәгънәсендә милләтебезнең күренекле шәхесе, атаклы җырчысы, татар халкының моңлы җырчылары Әлфия апа Афзалова, Хәния апа Фәрхетдинова кебекләрнең дәвамчысы булуына ышанып калабыз. Киләчәктә дә безне искиткеч моңлы җырлар белән сөендереп, татар халкының моңлы, аһәңле җырларын бөтен дөньяга танытып иҗат итәр дип чын күңелдән ышанып калабыз. Динә Гарипова- безнең горурлыгыбыз!

**Рифат Сәлах иҗатында яз фасылы**

Гомумбелем муниципаль бюджет учреждениесе

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль

районы 1 нче Лицей

Укучы: Сафина Әмирә Динар кызы

3 нче сыйныф укучысы

Кереш

« Мин язларны сөймим...

Ник яратыйм-...»,

дип яза Рифат Сәлах үзенең «Мин язларны сөймим» шигырендә. Шушы шигырь юллары безне фәнни эзләнүгә этәрде. Язны яратмаска мөмкинме? Шигъри сүзләр генәме болар, әллә шагыйрьнең күңел халәтеме? Гомумән, шагыйрь иҗатында яз фасылы ничек ачыла? Сорауларга җавап табу өчен, шагыйрьнең исемендә яз образы булган шигырьләренә мөрәҗәгать иттек. Безнеңчә, Рифат Сәлах поэзиясе образлар дөньясы, шигъри сурәт тудыру үзенчәлеге ягыннан шактый кызыклы. Шуңа күрә бу тема бик актуаль дип уйлыйбыз. Әлбәттә, бер эш кысаларында гына шагыйрь тудырган образлар галереясын ачыклап, аларга бәя биреп бетерү мөмкин түгел. Шул сәбәпле тикшеренү эшендә аерым бер юнәлеш сайланды, шагыйрьнең шигырләрендә «яз» образының бирелеше, яратып кулланган ачышларын ачыклау һәм, шулардан чыгып, яз фасылына бәйле шагыйрьнең күңел халәтен чагылдырган образларны билгеләү максаты куелды.

Фаразлау. Лирик герой язны яратмый дип уйлыйк.

Бурычлар:

- шигырьләрен анализлау, образлар дөньясын барлау;
- яз фасылын шагыйрьнең күңел халәтенә бәйле булуын ачыклау.

Фәнни эшнең практик әһәмияте: конкрет мисаллар ярдәмендә үз фаразларыңны тикшерергә, дәлилләргә, текст белән эшләргә өйрәнү.

Тикшерү объекты булып Рифат Сәлахның шигъри иҗаты, аерым алганда, «Күңел бөртекләре», «Яшел ай» китаплары тора.

Тикшерү методлары – күзәтү, анализ һәм синтез, математик исәпләү юлы белән фаразны исбат итү, нәтиҗә ясау.

Эшнең төзелеше. Тикшерү кереш, төп өлеш, йомгаклау һәм әдәбият исемлегеннән тора.

## Төп өлеш

Шагыйрь иҗатында заман проблемаларын чагылдыра. Милләт, тел язмышы, табигать, мәхәббәт темалары аның шигырьләренең төп юнәлешен билгели. Без исә аның лирик шигырьләрендәге образларга күзәтү ясарга, яз фасылы белән бәйле образларга киңрәк тукталып, аларның кулланылу ешлыгын билгеләү максатын куйдык. Анализ өчен, Рифат Сәлахның «Күңел бөртекләре», «Яшел ай» китаплары алынды. Китапларда 281 шигырь тупланган, 13 шигырьдә яз атамасы урын алган. Казанның меңьеллыгына багышланган «Казанда меңенче яз» шигырендә татар тарихына мөрәҗәгать итә,
башкалабыз, халкыбыз белән горурлана:

Меңенче языңа керсәң дә,
Иң гүзәл шәһәр син дөньяда!

«Язлар сөю алып килә, диләр» , «Язгы өмет», «Язгы төн» шигырьләрендә язны сурәтләүнең яңадан-яңа төсмерләрен, чараларын, формаларын эзли, чөнки табигать күренешләре лирик геройның рухи халәтен, хис – кичерешләрен бөтен тирәнлегендә ачуга юнәлдерелгән.

Хыяллыңда апрель өмете
Күзләреңне янә тереләтте?

Табигать – сәнгатьнең мәңгелек сурәтләү өлкәсе. Рифат Сәлах та табигать, яз белән бәйле хисләрен шигырь юлларына күчергән. Пейзаж лирикасы

гаҗәеп табигать образларына ия. Аның шигырләрендә «серле ай», «якты кояш», «яшел урамнар, «ак шомыртлар», «шаян җилләр»кебек образлар лирик геройның тормышны, язны  күрү рәвешен ничек, аны бәяләвен ассызыклый. Ачык төсләр, җылы сүзләр белән яза шагыйрь, шуның белән укучыны да җәлеп итә.

Тикшерергә алынган беренче шигырьләрдә ук шагыйрьнең Яз образына мөнәсәбәтен күрдек. Димәк, фаразыбызга каршы килдек. Ярата, шагыйрь язны, ярата... Алга таба шигырьләргә күзәтүләр дәвам ителде. Шагыйрь язны төрле төсләргә, төрле халәтләргә кертә: «көзләр язы», «чәчәкләнгән язлар юлы», «язның соры өннәре», «язгы алма» һ.б. эпитетлар, чагыштырулар аша сурәт тудыра һәм шуның белән укучы күңелендә каршылык уята. Лирик геройның күңел халәте яз көне кебек алмашынып тора: болытлы да, кояшлы да, яңгырлы һәм аяз да:

Болытлары да юк бүген-
Күге аяз көн менә!
(Язгы идиллия)

Шагыйрь яз фасылын лирик геройның хис-кичерешләре, рухи халәте, яшьлек мәхәббәт тарихы белән бәйли, шуңа күрә Яз образы төрле яклап ачыла. «Мин язларны сөймим» дигән өзектән башланган иде эш. Кабат шуңа әйләнеп кайтыла:

Мин язларны сөймим,
Тик көзләрдә-
Килми мәңгелеккә каласым.
... Үзең генә мине өр-яңадан
Язга гашыйк итә аласың!

Лирик герой үзенең мәхәббәтен сагына, язларга гашыйк булып, кабат очрашуга өметләнә.

Шагыйрьнең үзенә килсәк, игътибарны «Язларыма кайтам» әсәре җәлеп итә. Ул үзе дә язларга кабат әйләнеп кайта.

Күңелемә кунган кояш белән

Язларыма кайтып киләмен.

## Йомгаклау

Лирик герой язга булган яратуын үз мәхәббәте белән бәйли , юана, киләчәктә бәхеткә өметләнә. Әйе, шагыйрьнең шигъри таланты бер укучыны да битараф итми: шатландыра, күңел кылларын тибрәндерә, дулкынландыра, әмма хиссез калдырмый. Аның төрле шигъри үлчәмнәре, төрле шигъри формалары әдәбиятта үзенчәлекле алымнар буларак билгеләнә. Рифат Сәлах шигырьләрендә өмет, сөю, бәхет белән хисләрен чагылдыра, ритм-рифмасын шатлык интонациясенә «көйли» һәм төрле яңгыраштa бирә. Әле яңа гына дөнья күргән «Ак фәрештә» җыентыгында да Яз образына мөрәҗәгать дәвам итә:

Язны эзлим... Түбәләрдә кояш

Яз сулышын бөрки кояш үзе.

Бер сусаган чагым яшеллеккә

Яз һәрвакыт була яшел күзле.

Шагыйрь яшел күзле язны сөяме? Әлбәттә, сөя, ярата.... Бу сорауга җавап бирү өчен берничә шигырьгә күзәтү ясалды. Яшел төс... Яз җитү белән табигать яшеллеккә төренә,ә яшел төс - тормыш, тере табигать төсе**,** яшел төс –яшәеш символы. Яз образына шагыйрь төрле мәгънә бирә һәм яратуын раслый.

**Ленар Шәех шигырьләрендә кеше исемнәре**

Яшел Үзән районы Усман Әлмеев
исемендәге Акъегет төп гомуми белем бирү мәктәбе

Зиганшин Фирзәр Фәрид улы ,

4 нче сыйныф укучысы

## 1.Кереш өлеш

Мин, Зиганшин Фирзәр Фәрид улы, Усман Әлмеев исемендәгеАкъегет төп гомуми белем бирү мәктәбенең 4 нче сыйныфында белем алам.

Минем яраткан шөгылем – китап уку. Мәктәп һәм авыл китапханәсеннән алып төрле китаплар укыйм, аларны әти-әниемә , иптәшләремә, яраткан апама сөйлим. Уку дәресләрендә без бик күп шагыйрьләр, язучылар , аларның әсәрләре белән танышабыз. Шул әсәрләрдәге геройлар белән бергә яшибез. Мин үзем бигрәк тә шигырьләр укырга яратам. Үземә ошаганннарын ятлыйм, блокнотыма язып барам. Соңгы араларда Ленар абый Шәех шигырьләре белән кызыксына башладым.Чөнки аның шигырьләре җырга салынган көй кебек җиңел укыла. Һәм аның әсәрләрендә кеше исемнәренең күп кулланауына игътибар иттем. Бу миндә зур кызыксыну уятты. Кем ул Ленар абый Шәех? Аның геройлары  кемнәр? Исемнәр нинди мәгънәләргә ия? Һәм шуннан соң укытучы апам Гөлназ Гусмановна белән эзләнү эшен башлапҗибәрдек.

**Проектның исеме: “Ленар Шәех шигырьләрендә кеше исемнәре”.**

**Проектның максаты:** Ленар Шәехның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу;

шигырьләрдәге кеше исемнәрен барлау, аларның  мәгънәләрен ачыклау.

## 2.Төп өлеш

Шагыйрь Ленар абый 1982 нче елның 4 октябрендә Актаныш районы Такталачык авылында дөньяга килә. 1998 нче елда Такталачык урта мәктәбен, 2002 нче елда Минзәлә педагогия көллиятен , 2007 нче елда Казан дәүләт университетын тәмамлый. Студент булган вакытларда ук төрле газета-журналларда журналист булып эшли. Иң беренче булып студентлар арасында “Тәрәзә” дип аталучы газетаны оештыра. Ленар абыйның хәзерге вакытта шигырьләр җыентыгы басылган, шуларның күбесе балалар өчен язылган.

Ленар абыйның тормышы белән якыннанрак танышу өчен без укытучы апа белән аның әнисе Лениза апа, беренче укытучылары Сәбилә апа , татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әлфия апа әйткән фикерләрне таптык.

Ленар абыйның шигырьләр язу осталыгы әнисеннән күчкән икән. Чөнки Ленизa апа да бик матур шигырьләр яза.

Беренче укытучысы Сәбилә апа сөйләгәннәрдән: “Ленар 7 яше тулганчы укырга керде. Бик шаян, шук, тиктормас укучы иде. Мәктәпкә бик авыр ияләште. Башка балалардан аерылып тормады. Рәсем ясарга ярата иде. Шигырьләр язу осталыгы сизелмәде. Шулай да, җавап биргәндә, такмаклап җавап бирә торган гадәте бар иде”.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әлфия апа: “Өлкән классларда укыганда Ленар бик тыйнак булды. Сочинениеларны бик матур итеп яза иде. “Соңгы кыңгырау” бәйрәмендә үзе язган шигыре барлык кешеләргә тәэсир итте. Минзәлә педагогия училищесында укыганда туган мәктәбенә практикага кайтты. Такталачык урта мәктәбе укучылары иҗаты яктыртылган “Гөлчәчәкләр илендә” җыентыгын бастырып чыгарырга үзеннән зур өлеш кертте. Ленар һәр яңа чыккан китабын мәктәпкә бүләк итеп тора. Без аның белән бик горурланабыз!”

Ленар абыйның шигырьләре бик кызыклы. Анда балалар тормышы чагыла. Ул безне яратып та, иркәләп тә, шелтәләп тә ала. Мине бигрәк тә шигырьләрдәге кеше исемнәре кызыксындырды.

**Нәрсә соң ул исем?**

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә "исем"сүзенә түбәндәге аңлатма бирелә: "Исем"- кешегә тугач та бирелә торган шәхси атама. "Татарча милли

исемнәр татарлыкны, татар халкының милли йөзен, төсен, сыйфатын, тарихи үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген тиешенчә яклый һәм саклый."

**Балалар шагыйре Ленар Шәех үзенең иҗатында геройларына ниндирәк исемнәр сайлады микән?**

“Авылдан килгән мендәр”, “Керпе ничек энәле белган?”, “Безнең ишегалдында”җыентыкларыннан 74 шигырь укып, андагы геройларның исемнәре белән танышып чыктык. Шигырьләрдә 30 кеше исеме кулланылган. 16 сы – малайлар исеме, 14 е – кызлар исеме. Тикшерү эшен дәвам итеп, шул исемнәрнең мәгънәләрен ачыкладык.

**“Чаңгы, чана шуар чак”шигырендә**

Гөлгенә – татар исеме. Тоташ гөлдән торган мәгънәсендә.

**"Картлар нигә шатлар?"шигырендә**

Хәй – гарәп исеме.Тормыш, яшәү дигәнне,

Вәли – гарәп исеме .Ия, хуҗа һәм якын кеше дигәнне,

Зәйнәп – гарәп исеме. Борынгы исем.

**"Кем кем була?"шигырендә**

Илшат – татар исеме, ил һәм шат сүзләреннән ясалган; ил шатлыгы дип аңларга мөмкин.

Илгиз – татар исеме. Ил һәм гизү дигәнне,

Йолдыз – төрки халык исеме. Йолдыз кебек дигәнне аңлата.

Ленар Шәех үзенең әдәби геройларына куйган исемнәрнең күпчелеге халкыбызга гарәп – фарсы теленннән кергән, 8 исем- саф татар исеме. Фәкать Марат исеменең генә француз теленнән кергәнлеге ачыкланды.

Укытучы апа белән тагын шуңа игътибар иттек: аның иҗатында шактый авылдашларының исемнәре үзгәртмичә бирелә. Мәсәлән, “Сәет бабай” – Бөек Ватан сугышы ветераны Таҗиев Сәет бабай турында . “Таш атучы Рузалин” – шигырендәге төп герой Рузалин – аның сыйныфташы.

Исемнәр турында фикер алышкач, мин үземнең исемнең мәгънәсен дә ачыкладым.Фирзәр –төрки халык исеме.Җәннәт алтыны дигәнне аңлата.

## 3. Нәтиҗә

Ленар абый исемнәр сайлауга бик таләпчән караган. Иҗатында бер генә очраклы исем дә юк. Аның геройларының исемнәре чорларга туры килә. Мәсәлән, **“Картлар нигә шатлар**” шигырендә ул өлкән кешеләргә шул дәвер исемнәрен куша – Хәй, Нури, Әскап, Вәли, Мәрьям, ә балаларга - Фәнил, Азат, Гөлгенә ,Илдар – хәзерге чорга туры килә.

Ленар абыйның гаиләсендәге кешеләр исемнәре дә бик матур. Айсылу апа белән ( ул да шагыйрә) Гали исемле малай,Таңсылу исемле кыз үстерәләр.

Ленар Шәех 2013 елда Татарстан Республикасының Муса Җәлил исемендәге Республика премиясенә, 2015 елда “Волга – 2015» Идел буе әдәби премиясе лауреаты , 2017 елда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге әдәби премиясенә ,шул ук елда Швециянең Стокһольм шәһәрендә узган VI Халыкара әдәби фестивалендә "Әдәби әсәр" категориясендә "Кече проза" номинациясендә (бәйгенең Гран-прие) икенче урынны ала. 2018 елда Халыкара Евразия премиясенең алтын лауреаты дигән мәртәбәле исемнәр бирелә.

Мин үзем Ленар абый белән бик нык горурланам. Чөнки аның иҗаты һәркемдә соклану уятырлык.

**Ленар Шәех – шигырьләр яңгыры**

Гомумбелем муниципаль бюджет учреждениесе

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль

районы 1 нче Лицей

Эшне башкарды:Гараева Азалия Азатовна
4а сыйныфы укучысы

**Кереш.**

Мин татарча шигырьләр сирәк укыйм, күбрәк әкиятләр укыйм. Ә менә кечкенә энемә китап эзли башлагач, китапханәдә бик матур яңа китаплар бирделәр. Башта рәсемен генә карады энем, аннары укырга кушып арттан йөри башлады. Укыгач, шигырьләр уку да кызык икән дигән нәтиҗәгә килдем. Энемә дә шигырьләр бик ошады, көн дә укытып йөдәтеп бетерде. Бу авторның башка китапларын да алып укырга туры килде. Укытучы апабыз яшь язучылар турында язарга тәкъдим иткәч, шунда ук әлеге шагыйрь турында искә төшердем.Әлеге шәхесне өйрәнергә, кабат китапларын ачарга, укырга кирәк булды.

Теманың актуальлеге: Хәзер татарча әсәрләр, бигрәк тә шигырьләр укучылар сирәгәйде. Татар телен белгән, укырга теләгәнәрне дә кызыксындыру авыр. Шуңа күрә сайлаган теманы кирәкле һәм мөһим дип саныйм.

Ленар Шәехнең балалар өчен иҗатын, шигырьләрен өйрәнеп махсус нәтиҗәләр ясап чыгарылган хезмәтләр аз. Ләкин аның шигырьләре актуаль, кирәк.

Эшнең максаты булып Ленар Шәехның балалар өчен иҗатына күзәтү ясау. Максатыма ирешү өчен түбәндәге бурычларны куйдым:

1. Л.Шәехның балалар өчен чыккан китапларын туплау һәм өйрәнү.
2. Л.Шәех турында материалларбелән танышу.

3. Шагыйрьнең әсәрләренә күзәтү ясау.
4. Л.Шәех шигырьләренең балаларга файдасын билгеләү.

Тикшерү объекты булып Ленар Шәехнең балалар өчен иҗаты алынды. Тикшерүнең предметы: аның иҗатында балаларны кызыксындыру, тәрбияләү чаралары.

Хезмәт – кереш, төп өлеш, төп өлеше үзе ике бүлектән, әдәбият исемлегеннән тора.

## 1 бүлек. Балалар әбиятында Ленар Шаехнең иҗаты.

### 1.1 Ленар Шәех кем ул?

Шагыйрь, журналист Ленар Шәех (Ленар Миңнемөһим улы Шәехов) 1982 елның 4 октябрендә Татарстан Республикасы Актаныш районы Такталачык авылында туа. Такталачык урта мәктәбендә укыганда, Ленар төрлечә яза башлый. Аның “Адашлар” исемле иң беренче язмасы 1994 елда “Игенче даны” (хәзерге “Актаныш таңнары”) район газетасында чыга. Алтынчы сыйныфта укыганда “Безнең гаилә” дип исемләнгән беркенче шигырен яза.

Минзәлә педагогия көллиятендә укыганда аның әсәрләре бер-берартлы республика матбугатында күренә башлый. “Сабантуй” газетасында “Сөйгәнем” дип исемләнгән шигыре басыла. ШулвакыттааныТатарстанныңхалыкшагыйреИлдарЮзеевкүреп ала. Уланыңталантлышагыйрьбулачагынәйтә.“Соңгы елларда “Сабантуй” газетасында эшләү дәверендә, шагыйрь мәктәптә туа дигән күптәнге уема янә бер тапкыр инандым. Балачактан кочак-кочак шигырьләр ява! Тәүге кар кебек саф, ләйсән яңгырыдай сөенечле. Иң күп шигъри хисләрне Актаныш ягыннан искән ягымлы җилләр китерә. Әлфия Авзалова кебек моңлы җырчыларны, Гамил Афзал кебек шагыйрьләрен халкыбызга бүләк иткән як бит! Кабатланмас гүзәл табигать талантларны, бәлки, күбрәк тудырадыр.

Гамил Афзалның туган авылы Такталачыктан шагыйрьләрен җибәреп торган Ленар башкалардан йөз саескан арасындагы сыерчык кебек аерылып тора

иде. Үзенчә сайраргa омтылуы миндә өмет уятты. Ленар чын мәгънәсендә “Сабантуй” да туды. Әлегә мин Ленарны, үзе язганча, “бөре ачкан зирек” халәтендә күрәм. Колач җәйгән зирекләрнең матур шаулавын еракларга ишеттереп, шигъриятнең авыр юлларыннан барасы да барасы!”,- дип яза Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев. (1)Университетта укыганда, язучы Галимҗан Гыйльманов белән бергә уку йортының легендар “Әллүки” әдәби-иҗат берләшмәсен кабат сафкабастырып җибәрә һәм бик күп төрле әдәби эшләрне берьюлы алып баручы актив язучыга әйләнә.

Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе, Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия, VI Халыкара “Ачык Евразия“ әдәби фестивалендә “Кече проза“ номинациясендә II урын иясе. Филология фәннәре кандидаты. Татарстан һәм Русия Журналистлар берлеге әгъзасы, Халыкара Журналистлар Ассоциациясе, Халыкара ПЕН-клубның Татар ПЕН-үзәге, “Евразия иҗат гильдиясе“ (Лондон) әгъзасы. 2008 елдан бирле Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире вазифасын башкара. Бу көздә исә Халыкара Евразия премиясенең алтын лауреаты дигән мәртәбәле бүләккә лаек булды. (1) Аның иҗаты Татарстанда гына түгел, чит илләрдә дә таныш. Аның китаплары татар, рус, башкорт, кыргыз, чуваш, якут телләренә тәрҗемә ителгән. Интернет челтәрендә аның тагын бер зур уңышы - китапларының инглиз телендә дә басылып чыгуы хәбәр ителә.

## 1.2 Балалар өчен нинди әсәрләр яза?

Ленар Шәехның шигырьләрендә темалар күп төрле. Шагыйрь табигатькә сак караш тәрбияләү турында да яза. Мәсәлән “Уңай сыйфатлар”, “Күлдә” шигырьләре. Шулай ук “Ни өчен куянның колагы озын?” әкиятендә шагыйрь табигатькә соклана, ике зур җәнлекне чагыштыра, куянның куркаклыгын күрсәтеп бирә. Шагыйрь иҗатында кызыклы, мавыктыргыч шигырьләр дә күп: “Каратист”, “Торт”, “Башым катты”.

Хезмәт темасы, хайваннар дөньясы, “Безнең ишегалдында” китабында күрсәтелгән. Ленар Шәех үзенең иҗатында балалар тәрбияләү, хезмәтне

яратып үсәргә, шулай ук бала булып кала белергә, тапкыр, югалып калмаска, мәрхәмәтлек темаларына таянып эш иткән.

Ленар Шәех иҗатында авыл турында, авыл тормышына кагылышлы бик күп шигырьләр бар. Шигырьләре бик кызык, мавыктыргыч итеп язылган.Ленар Шәех – балалар өчен "Авылдан килгән мендәр" (2005), "Керпе ничек энәле булган?" (2007), "Безнең ишегалдында" (2010, 2012), "Алдамыйм!" (2014) исемле китаплар авторы. Ленар Шәехнең "Авылдан килгән мендәр" (2005) китабындагы шигырьләре төрле яшьтәге балаларга адресланган. Аларда - мәктәп тормышындагы кызыклы вакыйгалар да ( "Мин "бишле" алгач","Физкультура дәресендә", "Башым катты" һ.б.), гаиләдәге мәнәсәбәтләр дә ( "Безнең гаилә", "Мин кем малае?" һ.б), эшкә өйрәтү дә ("Әнисенең киңәше"), начарлык эшләүнең үзеңә кире кайтуын күрсәткән гыйбрәтле хәл дә ("Таш атучы Рузалин"),милли рух та ("Татарлык"), балалар арасындагы мәхәббәт тә ("Яхшы гамәл") чагылыш тапкан.
"Яшь шагыйрь бигрәк тә балалар шигъриятендә ихлас һәм самими, тапкыр һәм зирәк. Һәр татар кешесенең күңелендә сабый чактан тәрбияләнә торган моң яши. Шагыйрь, үзе әле яңа гына сабыйлыктан чыккан кеше булса да, нәни дусларына хәзердән үк яшәү мәгънәсен төшендерергә омтыла. Моның өчен тормыштагы кызык хәлләрне генә түгел, гыйбрәтле, гамьле һәм сагышлы язмышларны да сурәтләргә алына", - дип яза язучы Галимҗан Гыйльманов.

## 2нче бүлек. Ленар Шәех балаларны нәрсәгә өйрәтә?

Ленар Шәех үзенең иҗатында балаларның өлкәннәргә карата мөнәсәбәтен, ихтирамлы, инсафлы булып үсүләренә, өлкәннәргә карата хөрмәт, гаилә темасына кагылышлы шигырьләре дә шагыйрьнең иҗатында бик актуаль, тормышчан. Мәсәлән, "Әнинең киңәше" шигырендә, әни кызын тегергә, чигергә өйрәтә. "Сает бабай" шигырендә шагыйрь "хәрәкəттә-бәрәкәт" дип, хемәтне мактый. Бабай сиксән яшьтә булуына карамастан ул шук, шаян, тырыш, тапкыр итеп сүрәтләнгән. Эшләгән эшләренә сокланып, егетләргә сөенеп яшәгән Сәет бабай образы күрсәтелгән. Шагыйрьнең

“Авылдан килгән мендәр” җыентыгында төрле темаларга язылган шигырьләре урын алган. Ел фасылларына кагылышлы шигырьләр, бишек җырлары да чагылыш тапкан.Үзенең шигырьләре аша шагыйрь тәрбияләп кенә калмый, белемнәрен арттыра һәм сөйләм телен камилләштерергә алына. Л.Шәехның шигырьләре балаларга аңлаешлы, мавыктыргыч, яттан өйрәнү өчен җиңел.

Ленар Шәехның шигырь китабына күз салсаң, мәсәлән “Җылытасы килә дөньяны!...”. Яшәгән дөньяны җылытырга этәргеч ясый. Язган шигырьләр бөтен дөньяны җылыта алмас, әлбәттә. Әмма ул күңелләрне җылыта, ә күңеле җылы кешеләр дөньяны җылыта.

Күп кенә шигырьләре көйгә салынган, халык яратып җырлый, тыңлый. Берсеннән- берсе мәрхәмәтле, берсеннән - берсе шәфкатьле җырлары беләнхалык күңеленә кереп урнашты шагыйрь. Аның җанга шифа бирә табигатькә, матурлыкка багышланган шигырьләре күп: “Җәй үтеп бара сыман”, “Биек таулар, киек таулар көтә сыман”, “Күзләр” һ.б.

«Җил каян килә?» китабы балалар һәм яшүсмерләр өчен кызыклы фәнни-популяр басма булып тора. Аның шигырьләре балаларны, дуслыкка, яратырга, мәрхәмәткә өйрәтүче, тугры юл күрсәтүче булып торалар.

## Йомгаклау.

Л.Шәехның шигырьләре тапкыр, җитез булырга өнди. Ул аларны шаян шигырьләре аша күрсәтә. Һәр бала әдәбият дөньясына әкиятләр, шигырьләр аша килә. Үзенең шигырьләре аша әдип баланы тәрбияләп кенә калмый, ә белемен арттырырга һәм сөйләм телен камилләштерергә дә алына.

Максатыма ирешү өчен үз алдыма куелган бурычларны иҗат һәм тормыш юлын танышудан башладым, балаларга язылган әсәрләре белән таныштым, аларның эчтәлеге буенча нәтиҗәләр чыгардым.

Ленар Шәехның шигырьләрен алга таба да укып барырга, аның уңышларын күзәтеп барырга кирәк дигән нәтиҗә ясадым. Ленар Шәехның шигырьләре телебезнең матурлыгын, байлыгын аңарга,

аның сиземләргә,үземдә һәм бәләкәй энемдә күркәм сыйфатлар булдырырга, тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә, туган телебезгә мәхәббәт, тыйнаклылык, шәфкатьлелек сыйфатлар булдырыга ярдәм итәр дип ышанасы килә.

Һәр кешегә Ленар Шәехның шигырьләре балаларда туган теленә мәхәббәт уяту өчен файдалы кулланма булып хезмәт итәр дип уйлыйм.

**Ленар Шәех иҗаты**

Татарстан Республикасы

Зеленодол муниципаль районы “10 нчы гимназия”

муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

3А сыйныфы укучысы Баязитова Камилә

Мин-татар кызы. Туган телемне бик яратам. Татар телендәге китапларны да бик теләп, яратып укыйм. «Китап-бакча, андагы язулар-шул бакчаның гөлләре», –дигән бөек галим, якташым Каюм Насыйри. Мин үзем өчен бик кызыклы шагыйрь «ачтым». Ул–Ленар Шәех.

Хезмәтемнең максаты – Ленар Шәехнең тормышын һәм иҗат юлын ачыклау.

Бу максатка ирешү өчен мондый бурычларны алдым:
– Ленар Шәехнең тормыш юлын өйрәнү;
– Шагыйрьнең язган шигырьләрен , китапларын барлау, аларны укып өйрәнү, аларга үз мөнәсәбәтемне белдерү.

Шагыйрь, журналист Ленар Шәех (Ленар Миңнемөһим улы Шәехов) 1982 елның 4 октябрендә Татарстан Республикасы Актаныш районы Такталачык авылында дөньяга килә. Такталачык урта мәктәбендә белем алганда, Ленар каләм тибрәтә башлый, иҗатка тартыла. Аның «Адашлар» исемле иң беренче язмасы 1994 елда «Игенче даны» (хәзерге «Актаныш таңнары») район газетасында дөнья күрә. Алтынчы сыйныфта укыганда «Безнең гаилә» дип исемләнгән беренче шигырен яза. 1999-2002 елларда ул Минзәлә педагогия көллиятендә белем ала. Аның әсәрләре бер-бер артлы республика газеталарында күренә башлый. Беренче мәртәбә «Сабантуй» газетасында «Сөйгәнем» дип исемләнгән шигыре басыла. Педагогия көллиятен тәмамлагач, Л.Шәех Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетына укырга керә.

Университетта укыганда язучы Галимҗан Гыйльманов белән бергә «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсен кабат сафка бастырып җибәрә. «Әллүки» тирәсендә алтмышка якын яшь каләм иясе җыела. Шул ук вакытта берләшмәнең айлык басмасы — татар студентларының «Тәрәзә» газетасы чыга башлый. Л.Шәех аның нигезләүчесе һәм баш мөхәррире була. 2007 елны Татарстан китап нәшриятында «Әллүки» дип исемләнгән җыентык (төзүчесе—Ленар Шәех) басылып чыга.. Университетта белем алуы белән беррәттән, Л.Шәех 2004-2005 елларда — «Шәһри Казан», 2005-2007 елларда «Татарстан яшьләре» газеталарында журналист булып эшли. 2006 елда Германиянең Гиссен университетында студентларның «Kleineweltzeitung» газетасында дөнья күрә. Ленар Шәехнең мәкаләләре, шигырьләре, хикәяләре «Татарстан яшьләре», «Сабантуй», «Чаян», «Мәдәни җомга», «Казан утлары», «Сөембикә», «Идел», «Ялкын», «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Мәгърифәт», «Молодежь Татарстана», «Салават күпере»; Башкортстанның «Тулпар», «Шоңкар», «Йәшлек», «Кызыл таң» кебек газета-журналларында басыла. Л.Шәех — «Авылдан килгән мендәр», «Керпе ничек энәле булган?», «Дүртенче кат... Бишенче кат...» исемле китаплар авторы. Аның «Җил каян килә?» китабы балалар һәм яшүсмерләр өчен бик кызыклы.
2008 елда Татарстан китап нәшриятында Л.Шәех төзегән «Нәҗип Газизов» исемле китап чыга. Ул аның дәү әтисе — РСФСРның халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган мәктәп укытучысы Нәҗип Газиз улы Газизовның (1918-1977) якты истәлегенә багышлана.

2007 елдан Л.Шәех – Татарстан китап нәшриятының балалар һәм яшүсмерләр редакциясендә мөхәррир хезмәтендә. 2008 елдан ул Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире .

2013 елда Татарстан Республикасының Муса Җәлил исемендәге Республика премиясенә, 2017 елда Абдулла Алиш исемендәге әдәби премиясенә лаек була. 2015 елда «NEWBOOK.Волга – 2015» Идел буе әдәби премиясе

лауреаты була. 2017 елда Швециянең Стокһольм шәһәрендә узган VI Халыкара "Open Eurasian Literature Festival & Book Forum" әдәби фестивалендә "Әдәби әсәр" категориясендә "Кече проза" номинациясендә (бәйгенең Гран-прие) икенче урынны ала. 2018 елда Халыкара Евразия премиясенең алтын лауреаты дигән исем бирелә.

Л.Шәех – 2007 елдан Татарстан Язучылар берлеге, 2012 елдан Татарстан Язучылар берлеге идарәсе, 2016 елдан «Евразия иҗат гильдиясе» (Лондон) әгъзасы.

Ленар Шәехнең шигырьләрендә миңа иң ошаганы -аларның аңлаешлы , укырга җиңел булуы. Гаилә турындагы әсәрләренең берсе – “Безнең гаилә” шигыре. Бу шигырь балаларны тәрбиягә, эш эшләп үсәргә өйрәтә. Мин үзем шәһәр кызы булсам да, аның авыл, авыл табигате турында язган шигырьләрен яратам. Ленар Шәехнең кеше яшьтәге балаларга адресланган “Безнең ишегалдында” дип аталган шигырь җыентыгы бар. Әлеге китабында шагыйрь нәниләрне авыл ишегалдында яшәүче кош-кортлар, хайваннар белән таныштыра. Анда комда коенучы күркә дә, күлгә таба йөгерүче үрдәк тә, ара-тирә бакчага кергәләп чыгучы кәҗә дә, ишегалдын саклаучы эт тә һәм башка күп кенә йорт хайваннары һәм кошлары бар. Бу китабы укыр өчен кызык та, чөнки анда шигырьләр иллюстрацияләр белән баетылган.

Ленар Шәехнең “Авылдан килгән мендәр” (2005) китабындагы шигырьләре төрле яшьтәге балаларга адресланган. Аларда - мәктәп тормышындагы кызыклы вакыйгалар да (“Мин “бишле” алгач”, ”Физкультура дәресендә”, “Башым катты” һ.б.), гаиләдәге мәнәсәбәтләр дә ( “Безнең гаилә”, “Мин кем малае?” һ.б), эшкә өйрәтү дә ("Әнисенең киңәше"), начарлык эшләүнең үзеңә кире кайтуын күрсәткән гыйбрәтле хәл дә (“Таш атучы Рузалин”), милләтне ярату да (“Татарлык”), сурәтләнгән. Түбәндәге шигырь юлларына игътибар итик әле:

Әнием дә татар кызы.  
Әтием – татар улы.

Шулай булгач,үземдә дә

Минем татарлык тулы.

Татарлыгым – горурлыгым,

Йолдызның иң ачыгы,

Көннең иң нурлы кояшы,

Иртәнең иң саф чыгы...

Ленар Шәехнең балалар өчен язган шигырьләре табигать күренешләре, ел фасылларын, ай, йолдызларны сурәтли. Табигать, ел фасыллары турында бик матур итеп яза:

Елмая, көлә

Чибәр Язбикә.

Шатлык, сөенеч

Килә бит җиргә.

Әйе, яшь шагыйрь һәм журналист Ленар Шәехнең тормыш юлы һәм иҗаты һәркемдә соклану уятырлык! Аның язмалары укучыларны үзенә җәлеп итә, бәхәсләр уята... Ул үз сүзен әйтә белә. Ленар Шәех татар шигъриятенең танылган бер шәхесе булыр.

**Муса Җәлил премиясе лауреаты Ленар Шәехның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге**

Яшел Үзән районы Усман Әлмиев исемендәге
Акъегет төп гомуми белем бирү мәктәбе

Әлмиева Чулпан Радик кызы,
3 нче сыйныф укучысы.

1.Кереш өлеш.

Мин, Әлмиева Чулпан Радик кызы, Яшел Үзән районы Усман Әлмиев исемендәге Акъегет төп гомуми белем бирү мәктәбенең 3 нче сыйныфында укыйм.

Минем яраткан шөгылем – китап уку. Мәктәп һәм авыл китапхәнәсеннән алып төрле китаплар укыйм, аларны әти-әниемә,иптәшләремә сөйлим. Уку дәресләрендә без бик күп шагыйрьләр, язучылар, аларның әсәрләре белән танышабыз. Шул әсәрләрдәге геройлар белән бергә яшибез. Мин үзем бигрәк тә шигырьләр укырга яратам. Соңгы араларда Ленар абый Шәех шигырьләре белән кызыксына башладым. Кем ул Ленар Шәех? Минем проект эшемнең **темасы“ Муса Җәлил премиясе лауреаты Ленар Шәехның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге.”**

**Хезмәтемнең максаты:**

- Ленар Шәехның тормышын һәм иҗат юлын ачыклау, аның иҗат үзенчәлегенә бәя бирү.

Бу максатка ирешү өчен мондый **бурычларны** алдым:

- Ленар Шәехның тормыш юлын өйрәнү;
- Шагыйрьнең язган шигырьләрен , китапларын барлау, аларны укып өйрәнү, аларга үз мөнәсәбәтемне белдерү

- Шагыйрь хакында әдәби тәнкыйть мәкаләләрен барлау, аларны өйрәнү, алардагы фикерләрне үз күзаллавым белән чагыштыру .

2. Төп өлеш.

Республикабызның Муса Җәлил исемендәге премиясе ике елга бер тапкыр яшь авторларның, композиторларның, рәссамнарның иң яхшы дип табылган әсәрләре өчен бирелә. Ул республика премиясе буларак 2003 елдан яңадан торгызыла. Лауреатлар арасында танылган шагыйрьләр Рәзил Вәлиев, Роберт Миннуллин, Зөлфәт, Ренат Харис, композитор Рәшит Абдуллин, драматург Туфан Миннуллин, актер Равил Шәрәфиев һәм тагын бик күп мәдәният хезмәткәрләре бар. Әлеге премиянең дәрәҗәсе елдан ел арта бара. 2013 елда шагыйрь Ленар Шәех – “Дүртенче кат… Бишенче кат…”, “Җылытасы килә дөньяны!..” шигырь җыентыклары өчен Татарстан Республикасының Муса Җәлил исемендәге Республика премиясенә лаек була.

Ленар Шәех 1982 елның 4 октябрендә Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылында дөньяга килә. Такталачык урта мәктәбендә белем алганда, Ленар каләм тибрәтә башлый, иҗатка тартыла. Аның “Адашлар” исемле иң беренче язмасы 1994 елда “Игенче даны” (хәзерге “Актаныш таңнары”) район газетасында басылып чыга. Алтынчы сыйныфта укыганда тәүге шигырен дә язып карый. Ул “Безнең гаилә” дип атала.

1999–2002 елларда ул Минзәлә педагогия көллиятендә белем ала. Аның әсәрләре бер-бер артлы республика газета-журналларында күренә башлый, “Сабантуй” газетасында шигырьләре басыла. Шул вакытта аны Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев күреп ала. Ул Ленарга өмет баглап, аның талантлы шагыйрь булачагына ышаныч белдерә, бу хакта матбугатта язып чыга.

“Соңгы елларда “Сабантуй” газетасында эшләү дәверендә, шагыйрь мәктәптә туа дигән күптәнге уема янә бер тапкыр инандым. Балачактан кочак-кочак шигырьләр ява! Тәүге кар кебек саф, ләйсән яңгырыдай сөенечле. Иң күп шигъри хисләрне Актаныш ягыннан искән ягымлы җилләр

китерә. Әлфия Авзалова кебек моңлы җырчыларны, Гамил Афзал кебек шагыйрьләрен халкыбызга бүләк иткән як бит! Кабатланмас гүзәл табигать талантларны, бәлки, күбрәк тудырадыр.

Гамил Афзалның туган авылы Такталачыктан шагыйрьләрен җибәреп торган Ленар башкалардан йөз саескан арасындагы сыерчык кебек аерылып тора иде. Үзенчә сайрарга омтылуы миндә өмет уятты. Ленар чын мәгънәсендә "Сабантуй" да туды. Әлегә мин Ленарны, үзе язганча, "бөре ачкан зирек" халәтендә күрәм. Колач җәйгән зирекләрнең матур шаулавын еракларга ишеттереп, шигъриятнең авыр юлларыннан барасы да барасы!",- дип яза Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев. Остазының якты истәлегенә багышлап Ленар "Илдар абый" дигән шигырен яза:

*Күңелләрне телеп төшә,*

*Йөрәкләрне мең яралый*

*Синең юклык, салкын бушлык,*

*Илдар абый, Илдар абый...*

Педагогия көллиятен тәмамлагач, Л.Шәех Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетына укырга керә.

Университетта уку дәверендә, язучы Галимҗан Гыйльманов белән берлектә уку йортының легендар "Әллүки" әдәби-иҗат берләшмәсен кабат сафка бастырып җибәрә. "Әллүки" тирәсендә алтмышка якын яшь каләм иясе җыела. Шул ук вакытта берләшмәнең айлык басмасы – татар студентларының "Тәрәзә" газетасы дөнья күрә башлый. Ленар Шәех аның нигезләүчесе һәм баш мөхәррире була.

2007 елда Татарстан китап нәшриятында "Әллүки" дип исемләнгән җыентык дөнья күрә (төзүчесе – Ленар Шәех). Анда әдәбият мәйданына ныклы адымнар белән килүче егерме биш яшь каләм иясенең әсәрләре урын ала.

Университетта белем алуы белән беррәттән, Л.Шәех 2004 елда "Азатлык" радиосының Казан бюросында тапшырулар әзерли, 2004–2005 елларда "Шәһри Казан", 2005–2007 елларда – "Татарстан яшьләре"

газеталары журналисты була. 2006 елда Алманиянең Гиссен университетында бер айлык тел курсларында укып кайта.

Ленар Шәехның тормышчан, табигый, һәр вакыйганы тирәнтен аңлап, үз фикерен, үз мөнәсәбәтен ачык белдергән проблемалары, көн кадагына сугардай язмалары, публицистик мәкаләләре Ленарның публицистик мәкаләләре, шигырьләре, хикәяләре, яңа чыккан китапларга рецензияләре республика матбугатының барлык көндәлек басмаларында, Башкортстанның “Тулпар”, “Шоңкар”, “Йәшлек”, “Кызыл таң” кебек газета-журналларында даими басыла.

Ленар Шәех – балалар өчен “Авылдан килгән мендәр” (2005), “Керпе ничек энәле булган?” (2007), “Безнең ишегалдында” (2010, 2012), “Алдамыйм!” (2014) исемле китаплар авторы.
“Яшь шагыйрь бигрәк тә балалар шигъриятендә ихлас һәм самими, тапкыр һәм зирәк. Һәр татар кешесенең күңелендә сабый чактан тәрбияләнә торган моң яши. Шагыйрь, үзе әле яңа гына сабыйлыктан чыккан кеше булса да, нәни дусларына хәзердән үк яшәү мәгънәсен төшендерергә омтыла. Моның өчен тормыштагы кызык хәлләрне генә түгел, гыйбрәтле, гамьле һәм сагышлы язмышларны да сурәтләргә алына”, - дип яза язучы Галимҗан Гыйльманов.

Ленар Шәехнең “Авылдан килгән мендәр” (2005) китабындагы шигырьләре төрле яшьтәге балаларга адресланган. Аларда - мәктәп тормышындагы кызыклы вакыйгалар да ( “Мин “бишле” алгач”,”Физкультура дәресендә”, “Башым катты” һ.б.), гаиләдәге мөнәсәбәтләр дә ( “Безнең гаилә”, “Мин кем малае?” һ.б), эшкә өйрәтү дә ("Әнисенең киңәше"), начарлык эшләүнең үзеңә кире кайтуын күрсәткән гыйбрәтле хәл дә (“Таш атучы Рузалин”) ,милли рух та (“Татарлык”), балалар арасындагы мәхәббәт тә (“Яхшы гамәл”) чагылыш тапкан.

Яшь булуына карамастан, Ленар берничә китап та чыгарып өлгерде. Өлкәннәр өчен дә, балаларга атап та. Шигырьләре, төрледән – төрле: формалары да, тематикасы да, тел – стиль үзенчәлекләре дә... Образлылык

ягыннан да, жанр нисбәтеннән дә үз-үзен кабатламаска тырыша. Балалар шигъриятендәге эзләнүләре дә кызыклы гына. Аның автор-төзүче буларак башкарган “Җил каян килә?” (2008) китабы балалар һәм яшүсмерләр өчен кызыклы фәнни-популяр басма булып тора.

2008 елда Татарстан китап нәшриятында Л.Шәех төзегән «Нәҗип Газизов» исемле китап дөнья күрә. Ул аның дәү әтисе – РСФСРның халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган мәктәп укытучысы, Актаныш районының 4 нче номерлы Яңа Әлем һәм 3 нче номерлы Такталачык балалар йортлары директоры, күренекле педагог, татар Макаренкосы Нәҗип Газиз улы Газизовның (1918–1977) якты истәлегенә багышлана.

Аның “Дүртенче кат... Бишенче кат...” (2008) исемле шигырьләр җыентыгы “катлар”га бүленгән. Бишенче кат- “мәхәббәт каты”. Аның мәхәббәт шигырьләренә дә еш кына нечкә шаянлык-наянлык, үткен сүз уйнатулар килеп керә... Мәхәббәтнең сихри көчен күрсәтә, аны яз гөле, яшь бөре, болытлар агышы, хисләрнең шашуы, күңелнең тынгысыз ярсуы һ.б. дип атый.

*Мәхәббәт- кояшның яктысы,*
*Мәхәббәт-дөньяның ак төсе,*
*Мәхәббәт-пакь айның чаткысы,*
*Мәхәббәт- дөньяның ак көче...*

Дүртенче кат -үзенең сагышлы, моңсу хисләрен ягымлы, ипле, моңлы бер шигъри тәртипкә китерә. Үзе өчен кадерле булган хәтирәләрне барлый. “Студент еллары”шигырендә болай дип яза:

*Мәңге сүнмәс учак булып,*
*Изге калын китап булып*
*Сакланыр ул, сакланыр,*
*Йөрәк түрендә калыр!*

Шулай ук “Агыйделдә боз китә”, “Соңгы яфрак”, “Иң якын дуска” кебек шигырьләре дә якты истәлек булып язылган.

Өченче кат – Ленар Шәех үз халкы турында уйлый, милләт язмышы өчен борчыла. Әлбәттә, шагыйрьне борчулы, фаҗигале хәлләр дә, тарихның шомлы мәлләре дә тетрәндерә. Шагыйрьнең кичерешләре ипле, алар, галибанә сүзләр булып, синең күңелеңә күчә. Һәм син шагыйрьнең тойгысын аңлавыңа куанасың. Аның “Дөреслек”, “Уян, татар!”, “Барыбыз да бер гамьле”, “Безнең тарих” шигырьләрендә татарның бүгенге реаль хәле, аның кыенлыклары, югалтулары, моң-зарлары чагыла.

Икенче кат- шагыйрьнең юморны да үз итүен күрәбез. Монысы да – шигырьләрен бизи торган матур сыйфат. “Декан буласым килә!”, “Тигезлек эзләгәндә”, “Бер гомеркәй җитми икән” һ.б. нечкә юмор хисе белән язылган.

Беренче кат- аның поэма, цикллары да игътибарны җәлеп итә. Шагыйрь укучыларын үз дөньясына чакыра... "Җылытасы килә дөньяны!.." (2011) дип исемләнгән бу китабында лирик һәм юмористик-сатирик шигырьләре, поэмалары урын алган. Ул үзенең тирән фәлсәфи фикерләре белән укучыны сискәндерә, уйландыра, нечкә юморы белән елмаерга мәҗбүр итә, туйганчы көлдерә. Җыентык шартлы рәвештә биш бүлеккә бүленгән. Ләкин бу китапны тоташы белән бер поэма дип атасаң да була.

“Мин өр-яңа шагыйрь Ленар Шәехның шигырь китабы кулъязмасын укыйм. Китапның исеме үк минем уйларымны куәтли: “Җылытасы килә дөньяны!..” Язган шигырьләребез бөтен дөньяны ук бер селтәнүдә җылыта алмас, әлбәттә. Әмма ул күңелләрне җылытсын, ә күңеле җылы кешеләр дөньяны җылыта лабаса... Укыйм, шигырьдән шигырьгә күчәм. Мине якты моң озата бара... Ленар затлы сөйләм серләрен белә. Көндәлек тормыш ыгы-зыгысыннан тинтерәгән күңелне затлы сөйләм сафландыра, терелтә. Чын шагыйрьнең көче әнә шунда...Бу иҗатның тагын бер сыйфаты күңелемә хуш килә: Ленар шигырьләрен фәлән-фәлән яшьтәге кешеләр өчен дип аерып язмый. Миңа калса, бу шигырьләрдән һәркем үзенә кирәкле җан җылысын табачак. Уз өр-яңа шигъри дөньяга сүзләр тылсымыннан хозурлан һәм кинән!”, - дип Ленар Шәехның иҗатына бәя бирә, Татарстан

Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Зөлфәт.

Ленар Шәех – Татарстан Журналистлар берлеге (2006 ел), Русия Журналистлар берлеге (2006 ел), Халыкара Журналистлар Ассоциациясе – IFJ(2006), Халыкара ПЕН-клубның Татар ПЕН-үзәге (2007 ел) әгъзасы. 2007 елдан Л.Шәех – Татарстан китап нәшриятының балалар һәм яшүсмерләр редакциясендә мөхәррир хезмәтендә. 2008 елдан ул Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире вазифасын башкара. 2012 елда Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры, филология фәннәре докторы Азат Әхмәдуллин җитәкчелегендә филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация яклый. 2013 елда шагыйрь Ленар Шәех – “Дүртенче кат… Бишенче кат…”, “Җылытасы килә дөньяны!..” шигырь җыентыклары өчен Татарстан Республикасының Муса Җәлил исемендәге Республика премиясенә лаек була.

Л.Шәех – 2007 елдан Татарстан Язучылар берлеге, 2012 елдан Татарстан Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы.

3. Нәтиҗә.

Әйе, яшь шагыйрь һәм журналист Ленар Шәехнең тормыш юлы һәм иҗаты һәркемдә соклану уятырлык! Аның язмалары укучыларны үзенә җәлеп итә, бәхәсләр уята... Һәрхәлдә битараф калдырмый. Чөнки ул үз сүзен әйтә белә, үткәрерлек итеп яза белә. Ленар Шәех татар шигъриятенең танылган бер шәхесе булыр. Ә камиллекнең аның чикләре булмый , эзләнүләр, табулар, югалтулар гомер буена дәвам итә.

**Үтәлми калган теләк**

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советлар Союзы Герое Николай Соболев исемендәге Васильево 2 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
Нигмәтҗанова Энҗе Алмазовна,_ 11сыйныф

1944 ел, гыйнвар. Беренче Балтыйк буе фронты.

